Җәлил хәзрәт Фазлыев

# ЛОКМАН ХӘКИМ

## НӘСЫЙХӘТЛӘРЕ

www.darul-kutub.com

Хузур – 1435/2014

ББК 86.38

Китап Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Экспертлар советы карары белән басарга хупланган.

**ҖӘЛИЛ ХӘЗРӘТ ФАЗЛЫЕВ. ЛОКМАН ХӘКИМ НӘСЫЙХӘТЛӘРЕ.** – Казан: Хузур-Спокойствие, 2014. – 64 бит. *Тулыландырылган икенче басма.*

Татарстан Республикасының баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның әлеге китабы Коръәндә исеме телгә алынган хикмәт иясе Локман Хәким нәсыйхәтләренә багышлана. Локман Хәким Дауд (г-м) заманында яшәгән булса да, аның нәсыйхәтләре бүгенге көн кешеләре өчен дә бик актуаль. Бу китап барлык кешеләр өчен дә көндәлек кулланма – өстәл китабы булып тора ала. Бу – бер кат укып чыгар өчен генә түгел, үзең өстендә эшләү, нәсыйхәтләрне тормышта куллану өчен.

Җәлил хәзрәт һәрвакыттагыча җиңел тел белән, тормышчан, гади һәм шул ук вакытта җитди әйберләрне җиңелчә шаяртулар аша да бирә алган.

© *Издательство «Хузур-Спокойствие»*

www.darul-kutub.com

### Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим

# Матур яшик

***Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гәәләмииин. Үәссаләәтү үәссәләәмү гәләә расүүлинә Мүхәммәдиү үә гәләә әәлиһи үә әсъхәәбиһи әҗмәгииин.***

***Газиз дин кардәшләрем, әссәләәмүгәләйкүм үә рахмәтүллааһи үә бәракәәтүһ!***

***Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга хәерле гомерләр, хәерле сәламәтлекләр биреп, гаиләләребездә бала кайгы-хәсрәте күрмичә, әти-әниләребезнең догасын алырлык иттереп, матур, күркәм рәвештә яшәүләрне насыйп итсә иде.***

*Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.)не искә алганда һәркайсыбыз үз-үзенә сорау бирергә тиеш: ул бу Җиргә ни өчен килгән, Аллаһы Тәгалә аны ни өчен җибәргән?..*

*Пәйгамбәребез (с. г. в.) әйткән: «Мин Җир йөзенә гүзәл әхлакны тәмам итеп урнаштыру өчен килдем». Пәйгамбәребез Мөхәммәдне (с. г. в.) искә алабыз икән, без һәрвакыт үзебезгә карарга тиеш: безнең әхлагыбыз нинди? Ул Пәйгамбәребез (с. г. в.) әхлагына туры киләме?..*

*Уйлап карасак, ислам динендә ике генә фарыз бар: берсе – Аллаһны тану, икенчесе – гүзәл әхлак. Калган фарызлар гүзәл әхлак тәрбияләү өчен бирелгән, шуңа күрә үтәү мәҗбүри, үтәмәсәң зур гөнаһлы буласың. Без намаз укыйбыз, ураза тотабыз, хаҗ кылабыз икән, ул безнең әхлагыбызда чагылыш*

www.darul-kutub.com

табарга тиеш. Әгәр намаз укып та, син телең белән кешене рәнҗетәсең икән, син намаз укымыйсың, бәлки гимнастика гына ясыйсың булып чыга...

Ә гүзәл әхлакны урнаштыру өчен Пәйгамбәребезгә (с. г. в.) Аллаһ Раббыбыз Коръән иңдергән, Пәйгамбәребез (с. г. в.) аркылы безгә фарызларны җиткергән. Без фарызларны үтәргә, хәрәмнәрдән тыелырга, Пәйгамбәребезнең (с. г. в.) Сөннәтләрен үтәп яшәргә тиеш. Күренекле галимебез Әхмәдһади Максудиның (1868-1941) «Гыйбадәте Исламия» китабында: «Коръәндә барлыгы 6226 аять бар», – диелгән. Дини чыганакларда: «Барлыгы бер миллионга якын хәдис бар», – дип хәбәр ителә. Болар һәммәсе дә – хакыйкатьтә, дүрт кагыйдәгә сыеп бетә. «Коръән һәм хәдис буенча яшим», – дип йөрүче дә, гомумән, һәркайсыбыз: «Мин шушы кагыйдәләрне үтимме?» – дип, үз-үзенә сорау бирергә тиеш.

Әхлакның иң **беренче кагыйдәсе** – Аллаһы Тәгаләне һәм Ул яраткан бөтен нәрсәне ярату; Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылу һәм беркемне дә сүкмәү. Пәйгамбәребез (с. г. в.) әйткән: «Мәрхәмәт кылган – мәрхәмәт кылыныр, сөйгән – сөелер, онытмаган – онытылмас». Икенче бер хәдисендә Мөхәммәд (с. г. в.): «Аллаһы Тәгалә сезгә әниегезгә караганда да якын», – дигән. Без җир йөзендәге һәркемгә, һәр кешегә, һәр җан иясенә мәхәббәт күзе белән карарга һәм аны яратырга тиеш. (Урамда яткан исерек тә искәрмә була алмый. Кайчак бездә хатын-кызлар: «Ничек тәгәрәп ята иде, күрдеңме?!» – дип, авыл буенча шуны сөйләп йөри. Хакыйкатьтә, болар барысы да Аллаһы Тәгаләнең күргәзмә әсбабы. Менә шундый кешеләр аркылы Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга да аракының нинди начар нәрсә икәнен күрсәтә. Беркемгә дә сер түгел: гайбәт сөйләгән кешене кайчак чәйнәп өзәсе килә башлый. Ә чынлыкта без исерек яныннан нәфрәтләнеп китәбез дә, шуның гайбәтен сөйләргә тотынабыз. Исерекне сөйләп-сүгеп йөргән кеше үзе үк, кибеткә кергәч, хәләл акчасына аракы сатып ала да, аны өенә алып кайтып куя. Хакыйкатьтә, исерекләр һәм гайбәт сөйләүчеләр һәрберебездә дә исерткечкә һәм гайбәткә булган нәфрәт хисе уятырга тиеш.

www.darul-kutub.com

*Локман Хәким дә: «Әхлаксыз кешене карап-күзәтеп әхлагымны төзәттем», – дигән. Менә шуңа күрә безгә әхлагыбызны үзгәртү, беркемне дә сүкмәү, һәр бәндәгә мәхәббәт күзе белән карау лазем. Кемдер ярамаган берәр нәрсә эшли икән, без шуннан гыйбрәт алып үзебезнең әхлагыбызны төзәтергә һәм шул кеше өчен: «Я Раббым! Бу бәндәңә тәүфыйк-һидәят бир», – дип дога кылырга тиеш.) Коръәни-Кәримдә болай диелә: «Яманнан тәүбәгә килеп, иман китереп, игелек кылганнарның яманлыкларын игелеккә алмаштырыр (кылган гөнаһларын ярлыкап, савaплы эшкә күндерер). Аллаһ ярлыкаучы, бик тә мәрхәмәтле» («Фуркан (Яхшыны яманнан аера торган Китап)» сүрәсенең 70 нче аяте). Кем дә кем тәүбәгә килеп, изге гамәлләр кыла башлаган икән, аның әүвәлге гөнаһлары юкка чыгачак.*

***Икенче кагыйдә*** *– Аллаһы Тәгаләнең бер мәхлукатына да зыян салмау. Без бер генә нәрсәгә дә зарар китерергә тиеш түгел. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) әйткән: «Мөэмин шул: кешеләр аннан үзләре һәм үзләренең маллары белән бәйле рәвештә үз-үзләрен кайгы-хәсрәттән имин дип хис итәр». Мөэмин, иман, иминлек – тамырдаш сүзләр. «Теленә, диненә, тән төсенә, милләтенә карамастан, мөэминнән бүтән кешеләр иминлек табар», – дигән (с. г. в.). Мөселман кем дигәндә, мөселман шул: «Аның кулыннан да, теленнән дә башкалар сәламәт булыр», – дип әйткән Пәйгамбәребез (с. г. в.). Хәдистә башка мөселманнарга карата гына иминлек күрсәтү турында сүз бармый, бәлки: «Теленә, диненә, тән төсенә, милләтенә карамастан, һәркем мөселман кешесеннән исән-имин булыр», – диелгән. Ислам, сәламәтлек, сәлам, мөселман сүзләре тынычлык дигән сүздән ясалган.*

***Өченче кагыйдә*** *– Аллаһы Тәгалә биргәнгә шөкрана кылу. Әгәр дә моннан ун/егерме/утыз ел элек булган тарихыбызга карап: «Кайчан әйбәтрәк иде?» – дип сорасалар, һич икеләнмичә: «Бүген», – дип җавап бирәчәкбез. Шулай булмыйни: торган өйләрне, йөргән машиналарны, кигән киемнәрне, ашаган ризыкларны моннан утыз ел элек булганы белән чагыштырырлык та түгел. Ә кайчан күбрәк зарлана башладык?! Билгеле, бөтенебез*

www.darulkutub.com

*дә: «Бүген», – дип әйтәчәк. Авызыбыз өч кенә төрле эш эшли: я зарланабыз, я гайбәт сөйлибез, я ашыйбыз. «Ибраһим» сүрәсенең 7 нче аятенә мөрәҗәгать итик: «Исегездәме, Раббыгыз сезгә: «Шөкер итсәгез, әлбәттә, сезгә (нигъмәтне) арттырачакмын, әгәр дә көферлек кылсагыз, һичшиксез, бирәчәк җәзам бик тә хәтәрдер», – дип хәбәр итте». Мин узган гасырның җитмешенче елларында гарәп хәрефләрен өйрәндем, Коръән укый башладым. Бу – комсомолга кергән еллар иде, моның өчен бераз шелтәләп тә алдылар. «Нишлисең? Ялгышасың бит!» – дип әйттеләр. Менә шул вакытта – XXI гасыр башында: «Җәлил космоска менә, Марска оча», – дип әйтсәләр, бөтен кеше ышаныр иде. Ә без комсомолга кергән шул елларда: «Җәлил Татарстан президенты белән янәшә басып гает намазы укыр, ә аның ярдәмчесе чалган корбаннар белән авыз ачар», – дисәләр, акылга җиңеләйгән диюләре бик мөмкин иде... Аллага шөкер, динебез чәчәк аткан көннәрне дә күрергә туры килде. Нинди зур сөенеч: Мәүлид бәйрәмнәрендә Хөкүмәт вәкилләре дә катнаша башлады. Аллаһы Тәгалә алга таба да ил-көннәребезгә иминлекләр биреп, Хөкүмәт җитәкчеләренә планлаштырган изге эшләрен башкарып чыгарга насыйп итсә иде. Безгә зарланудан туктап, шөкрана кылырга вакыт җитте. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.): «Әмирләрегезнең һәркайсына буйсыныгыз, һәр имамның артында торыгыз, хәтта шайтанны да сүкмәгез», – дип әйткән. Бер кеше ташка сөртенгәч: «Ах, шайтан монда таш куйган икән!» – дип, шайтанны сүгә, ә аты сөртенгәч: «Ах, карт алаша, шул ташны да күрмисеңмени?» – дип, атын кыйный икән... Шуңа күрә шайтанның гаебе юк, чөнки шайтан Аллаһы Тәгалә кушмаган эшне эшләми. Аллаһы Тәгалә шайтанга: «Мин Коръән иңдерермен, пәйгамбәрләр җибәрермен. Коръәнне үтәгән, Пәйгамбәрнең (с. г. в.) Сөннәтенә ияргән кешеләрне аздыру өчен синең көчең җитмәс», – дигән. Кемдер шайтан вәсвәсәсенә бирелгән икән, монда кем гаепле? Билгеле, гаеп ул кешенең үзендә. Монда шайтанның катнашы юк. Шуңа күрә гаепне үзебездән эзләргә, беркемне дә сүкмәскә, зарланмаска кирәк. Пәйгамбәребез (с. г. в.) хәдисендә болай диелә:*

www.darul-kutub.com

*«Кешегә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте ирешү һәм ул кешенең галимлеге шуннан беленер: ул үзендә булган хата-кимчелекләрне күрә башлар». Шулай булгач, кемнәрнеңдер гаеп-кимчелеген күрү өчен зур галим булу кирәк түгел, аңа наданлык та җитә. Рәсүлебез Мөхәммәд (с. г. в.): «Берәү үзендә булган берәр кимчелекне бетерсә, һиҗрәт кылган савап алыр», – дигән.*

***Дүртенче кагыйдә** – кирәкмәгән җиргә кысылмау. Халкыбызда бик матур мәкаль бар: «Ат дагалаганда бака ботын кыстырмый». Кешегә ярдәм итәсең, киңәш бирәсең, кемне дә булса өйрәтәсең килсә, бу гамәлне акылыңны эшкә җигеп, аның рөхсәте белән генә башкарырга кирәк. Хуҗа Баһаветдин хәзрәтләре: «Сез иң элек кешеләргә ничек итеп өйрәтергә кирәк икәнлеген өйрәнегез, чөнки берәү дә үзен өйрәткәнне яратмый», – дигән. Шулай итеп, ярдәм итәргә телисең икән, рөхсәт сорап, җайлап кына ярдәм итәргә, ярдәмне дә акыл белән эшләргә кирәк. Бер кеше аю белән дуслашкан. Бервакыт болар бергәләшеп юлга чыккан. Ял итәргә туктагач, аю кешене саклап торган. Кешенең битенә чебен кунгач, моның йокысы качмасын дип, аю теге чебенгә суккан. Шуннан соң теге кеше дә үлеп киткән. Әйтәсе килгән сүзем шул: ярдәмебез аюныкы төсле булмаса иде. Шуңа күрә Аллаһы Тәгаләнең һәр мәхлукатын яратыйк, берәүдән дә зарланмыйк, булганына шөкер итик. Кешеләргә киңәш биргәндә дә акыллы киңәшләребезне генә бирик. Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга да хәерле гомерләр насыйп кылса иде.*

www.darul-kutub.com

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим**

# Локман Хәким

**Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гәәләмииин. Үәссаләәтү үәссәләәмү гәләә расүүлинә Мүхәммәдиү үә гәләә әәлиһи үә әсъхәәбиһи әҗемәгииин.**

**Газиз дин кардәшләрем, әссәләәмүгәләйкүм үә рахмәтүллааһи үә бәракәәтүһ!**

## 1. Локман Хәкимгә хикмәт килүе

Аллаһ Раббыбыз Коръәни-Кәримдә («Локман» сүрәсе, 11 нче аять) әйтә:

﴿وَلَقَدۡ ءَاتَيۡنَا لُقۡمَٰنَ ٱلۡحِكۡمَةَ أَنِ ٱشۡكُرۡ لِلَّهِۚ وَمَن يَشۡكُرۡ فَإِنَّمَا يَشۡكُرُ
لِنَفۡسِهِۦۖ وَمَن كَفَرَ فَإِنَّ ٱللَّهَ غَنِيٌّ حَمِيدٞ ١٢﴾

«Үә ләкадь әәтәйнәә Лүкъмәәнәл хикмәтә әнишкүр лилләәһ, үә мәй йәшкүр фә иннәмәә йәшкүру линәфсиһ, үә мәң кәфара фә иннәллааһә ганиййүн хәмиид», ягъни «Хактыр ки, Без Локманга, Аллаһка шөкер ит, дип хикмәт (ачык зиһен, зирәклек) бирдек. Шөкер иткән кеше үзе өчен шөкер итәр. Шөкер итмәгән кеше исә, Аллаһ аның шөкеренә мохтаҗ түгел. Аллаһ бай, һәртөрле мактауга лаек».

www.darul-kutub.com

Нәрсә ул хикмәт – зирәклек? Ул – Аллаһ биргән акылың ярдәмендә, алган гыйлемеңне тормышта дөрес итеп куллана һәм башкаларга җиткерә белү. Без үзебезне иманлы кеше дип саныйбыз, күбрәк изгелек кыласыбыз, савап җыясыбыз килә. Риваятьләрдә килә, Муса (г-м) Аллаһтан «Син риза булсын өчен, рәхмәтеңә ирешү өчен нәрсә эшлим?» – дип сораган һәм Аллаһ Раббыбыз: «Бу бик җиңел, Мин биргән язмышыңа канәгать бул һәм шөкер ит», – дигән.

Иман китергәнбез икән, иманның бер шарты – тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан булуга ышану. Без байлыгыбыз, дәрәҗәбез артса, безне мактасалар, «бу эш үзебездән» дип уйлап, күңелдән горурлык үтә, я мактанып куябыз, шөкер итәргә онытабыз. Эш без уйлаганча барып чыкмаса, зыян күрсәк, тәнкыйтьләсәләр, түбән дәрәҗәгә төшерсәләр, зарланып, кемнедер гаепли башлыйбыз. Иманлы икәнсең – берәүне дә сүкмә, канәгать бул. Бу Аллаһның тәкъдире дип кабул ит.

Аллаһның хәерсез эше юк. Һәр эш артында бер хәер-сөенеч бар. Кыямәт көнендә кешеләр: «Нишләп безне үпкәләтүчеләр, рәнҗетүчеләр күбрәк булмады икән?» – дип әйтерләр, ди. Чөнки нигъмәткә шөкер итү нигъмәтне арттыра, сабыр итү Аллаһка якынайта һәм савапны арттыра. Безнең әбиләр: «Хәерле каза хәерсез дәүләттән артыграк», – диләр иде. Шуңа күрә дә Аллаһ Раббыбыз аятьтә: «Шөкер итсен өчен хикмәт бирдек», – ди. Аллаһның нигъмәтенә шөкер итеп бетерерлек түгел, чөнки шөкрана үзе дә Аллаһның нигъмәте.

Гыйлеме хикмәт дәрәҗәсенә җиткән кеше генә авыр вакытларда үзен тыныч тота һәм шөкер кыла ала.

Локман Хәким кешеләрне әдәп-әхлакка чакырып вәгазьләгән вакытында, берәү аны күреп, бик гаҗәпләнеп: «Син кол идең, көтүче идең, ничек бу дәрәҗәгә ирештең?» – дип сораган. Локман Хәким: «Әйе, мин – син әйткән шул кеше. Мин беркайчан ялган сөйләмәдем, әманәткә хыянәт итмәдем, барына канәгать булдым, мал артыннан кумадым, үземә кагылмаган әйберләргә кысылмадым», – дип җавап биргән.

Алган гыйлемнәребез бездә шушы сыйфатларны булдыра

www.darulkutub.com

алмаса, ул хикмәткә алып бармый, дөнья сазлыгына батырып безне һәлак итә.

Фөзәйл ибне Ияздан Һарун әр-Рашид патша: «Бурычларың бармы?» – дип сорагач, «Падишаһым, бурычларым бик күп, әмма син аны түли алмыйсың», – ди. «Мин дә түли алмый торган нинди бурыч ул?» – дигәч, «Аллаһ каршында бурычларым бик күп. Шуларны түләү белән мәшгульмен. Кыска гына гомер өчен, Аллаһ биргәненә риза булмыйча, бурычка кереп әйбер алырга оялдым», – ди. Аллаһ каршында иң зур бурычыбыз – шөкрана кылу һәм канәгать булу. Биш вакыт намаз укып, намаз арасында зарланып, кешеләрне сүгеп йөрисең икән – бу шөкрана түгел. Син намаз дигән бурычны җилкәңнән төшердең – рәхмәт баскычына күтәрелә алмадың.

Локман Хәкимгә хикмәт бирелү тарихы да гыйбрәтле. Аллаһ Раббыбыз Үзенең фәрештәләре аркылы аңа пәйгамбәрлек һәм хәлифә булуны тәкъдим итә. Локман Хәким: «Сайлау мөмкинлеге бармы?» – дип сорый. Уңай җавап алгач, икесеннән дә баш тартып: «Миңа бәлаләрдән сәламәтлек, гафият (исәнлек, саулык) кирәк. Пәйгамбәрләргә пәйгамбәрлек белән бәла килгәнен беләмен, янә хөкем кылучы олуг бәла эчендәдер. Әгәр дөрес хөкем итсә, хуш. Әмма золым кылса, урыны җәһәннәм. Миңа дөньяда түбәнлек, хурлык кылынып, ахирәттә газиз булу артыграк», – ди.

Бер мәзәкне искә төшерик. Аллаһ Раббыбыз өч сыйфат яраткан. Берсе – партияле булу (бүген партия халыкка түгел, властька күтәрелергә ярдәм итә), икенчесе – намуслы булу, өченчесе – акыллы булу. Һәркемгә шуның икесен генә сайларга кушкан. Я акыллы һәм намуслы буласың, әмма партиясез (хакимияттә түгел). Локман Хәким беренчесен сайлаган. Я намуслы һәм партияле, әмма акыллы түгел. Я акыллы һәм партияле, әмма намуслы түгел.

Пәйгамбәрлек һәм патшалыкка караганда гади кеше булуны артык күргәне өчен Аллаһ Раббыбыз аңа гыйлем һәм хикмәт бирә. Һәр сүзнең урыны, вакыты һәм кешесе бар. Шул үзенчәлекләр исәпкә алынмаганда сүзнең куәте булмый.

www.darulkutub.com

Коръән аятьләренең дә иңү тарихы, урыны, хәдисләрнең әйтелү тарихы, вакыты, кешеләре бар. Кулланганда шул үзенчәлекләрне, нечкәлекләрне белеп куллану зарур. Мөхәммәд әс-Сәләби үзенең Әбу Бәкер (р. г.) турындагы китабында, Әбу Бәкер әс-Ситдыйкның (р. г.) иң зур өстенлеге хакында язганда: «Ул Коръәнне яттан белә иде һәм тиешле урында, тиешле кешеләр янында тиешле аятьләрне китерә белә иде», – дип яза.

### 2. Локман Хәким Коръәндә әйтелгән нәсыйхәтләре

Локман Хәким хикмәткә ия булгач үзенең хатынын һәм балаларын бер Аллаһны гына танырга чакыра. Пәйгамбәребез (с. г. в.): «Һәр яхшы сүз – сәдака» – диде. Ә инде иң күркәм һәм иң яхшы сүз «Ләәә иләәһә илләлааа һ» кәлимәсе, шул сүз генә җәннәткә гарантия булып тора. «Сәдаканы үзеңнән һәм гаиләңнән башла» дигән хәдис бар. Үзең Аллаһны таныгансың икән, хатыныңны, балаларыңны Аллаһны берләргә (берлеген танырга) һәм зурларга өйрәт, хикмәт белән, сабырлык белән. Күп вакыт иң якыннарыңны өндәү читләрне өндәүгә караганда авыррак. Чөнки алар синең хакта башкалар белмәгәнне дә белә.

Локман Хәким улына нәсыйхәт кылып әйтте:

لَا تُشْرِكْ بِٱللَّهِ إِنَّ ٱلشِّرْكَ لَظُلْمٌ عَظِيمٌ ﴿١٣﴾

«Ләә түшрик билләәәһ, иннәшширкә ләзульмүн гәзыыыйм», – ягъни, «Син Аллаһтан башка берәр затка табынып ширек кылма. Хактыр ки, күп иләһләргә табыну, ширек кылу – зур кыерсыту» («Локман» сүрәсе, 13 нче аять).

Һәркемнең бәхетле буласы килә, һәркем бәхетне үзенчә эзли. Әмма иң зур бәхет – Аллаһны тану һәм тормышыңны Ул кушканча көйләү икәнен онытып җибәрә. Берәү бәхетне – дөнья малында, берәү – чибәрләрдә, берәү – дәрәҗәдә, берәү исерткечтә эзли, ләкин алар вакытлы һәм кеше теләгенә ирешсә дә, канәгатьлек кичерә алмый – югалтудан курка. Пәйгамбәребез (с. г. в.): «Исерткеч эчү потларга табынудан яман», – диде.

Өендә күлмәген ямап утырганда Хуҗа Насретдинның энәсе төшеп китә. Эзли, эзли, таба алмагач ишек алдына чыгып

www.darulkutub.com

эзли башлый. Аның энә эзләвен белгәч, берәм-берәм килеп күршеләре дә эзләшә башлый. Бишенче күршесе килгәч: «Син ул энәне кайда югалттың соң?» – дип сорый. Хуҗа: «Өйдә югалттым», – дигәч, күршеләре гаҗәпләнеп, бертавыштан: «Алайса нигә ишегалдында эзлисең?» – диләр. Хуҗа: «Монда яктырак бит», – дип җавап бирә…

Аллаһ Раббыбыз хакыйкый бәхетне дин эченә яшерде. Кем Аллаһны таныды – Ул кушканнарны үтәп, тыелганнарыннан тыелып, тормышын көйләде – бәхеткә иреште. Күңеле буш түгел – күңелендә Аллаһ. Ул белә – Аллаһ үзенең сөекле бәндәсен беркайчан да ташламый, мәңгелек сәгадәт-җәннәт аны көтә. Күп мәчетләр төзелде, Аллаһны танып, Ул кушканча яшәргә бөтен мөмкинлекләр бар, ләкин әле күпләрнең күңелендә Аллаһка урын юк. Аллаһ телләрендә генә. Әмма күңел буш тора алмый. Бүген җәмгыятебез шул бушлыкны исерткеч эчемлекләр, төрле мәгънәсез күңел ачулар белән тутырмакчы була – барып чыкмый, махмырдан тилмергән кеше кебек аңгы-миңге яшәвен дәвам итә. Локман Хәким, акыл иясе буларак, улын Бер Аллаһны гына таныргa, Аңа гына гыйбадәт кылырга, берәүне дә Аңа ширек кылмаска (Аллаһтан башка нәрсәләргә табыну иң авыр гөнаһ һәм көферлек) чакыра. Тормышында килеп чыккан уңайсызлыклар, читенлекләр өчен кемнедер гаепләп, сүгеп, каргап йөрисең икән – бу да ширекнең бер төре. Авыру-сырхау, бәла-каза да Аллаһның нигъмәте, ул сабыр итүчеләрне Аллаһка якынайта, әҗере җәннәт була.

Коръәни-Кәримнең «Әл-Бәкара (Сыер)» сүрәсендә яһүдләрнең алтын бозауга табынулары турында укып, гаҗәпләнеп калабыз. Аларны гаепләп вәгазьләр сөйлибез. Ул алтын бозауны һәркемнең өендә булган әйберләрдән койганнар, ягъни матди байлыктан. Бу аятьләр белән Аллаһ Раббыбыз безгә, ахирәтне онытып матди байлык артыннан гына куунының никадәр начар икәнлеген күрсәтә. Бүген кайберләребез кешеләр шаккатарлык өйләр төзи, бу ташка табыну түгелмени? Берәүнең максаты кешедә булмаган машина алу, аның өчен бар нәрсә эшләргә әзер. Бу тимергә табыну түгелмени? Татар халык шагыйре Габдулла Тукай да:

*Шаккатабыз тышкы зиннәтләр, киемнәргә карап;*
*Җан сатабыз әллә нинди вак «тиеннәргә» карап («Тәләһһеф»),*
– дип язды.

Кемдер кеше хакына кереп, алдап-йолдап акча җыя, бу сурәткә табыну түгелмени?

Әлбәттә, булдыра алсаң, яхшы өйләр дә салырга, яхшы машиналарда да йөрергә, матур киенергә дә кирәк, ләкин болар хәрәм юл белән, гамәл-гыйбадәтләр кылмыйча табылырга тиеш түгел.

Пәйгамбәребезгә (с. г. в.) бер кызны хатынлыкка тәкъдим итәләр, иң зур өстенлеге итеп «аның бер тапкыр да авырганы юк» диләр. Рәсүлүллаһ (с. г. в.): «Алайса ул Аллаһның сөекле бәндәсе түгел», – дип баш тарта, «Аллаһ авыруны яраткан кешесенә генә бирә», ди.

Балаларыбыз дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булсын дисәк, аларны Аллаһны танырга һәм аның хөкемнәренә риза булып яшәргә өйрәтү – һәр ата-ананың бурычы. **Әгәр кечкенә вакытта балага Аллаһ турында бик күп сөйләмәсәң, картаймыш көнеңдә Аллаһы Тәгаләгә балаң турында бик күп сөйләргә туры киләчәк.**

Нәсыйхәтен дәвам итеп, Локман Хәким улына: «Йәә бүнәййә иннәһәә иң тәкү мискаалә хәббәтим мин хардәлиң фәтәкүң фии сахратин әү фиссәмәәүәәти әү фил әрдый йәәти биһәллааһ, иннәллааһә ләтыыйфүн хабииирь. Йә бүнәййә әкыймиссаләәтә үәәмүрь бил мәгрууфи үәнһә гәнил мүңкәри үәсъбир гәләә мәәә әсаабәк, иннә зәликә мин гәзмил үмүүүрь. Үә ләә түсәгирь хаддәкә линнәәси үә ләә тәмши фил әрдый мәрахәә. Иннәллааһә ләә йүххиббү күллә мүхътәмиң фәхууур. Үәкысыйде фии мәшйикә үәгъдудь мин саүтик, иннә әңкәраль әсъүәәти ләсаүтүл хәмииирь», ягъни «Әй, улым, (игелекме ул, яманлыкмы) кылмышың гәрчич бөртеге хәтле генә булып, ул да тау кыясына яки күкләргә, яки җир астына яшеренгән булса да, Аллаһ (кыяматтә) аны синең каршыңа чыгарып куяр. Хактыр ки, Аллаһ иң нечкә – яшерен эшләрне дә күреп-белеп тора, Ул бар нәрсәдән хәбәрдар. Балам, намазыңны укы, (башкаларны) игелеккә өндә, яманлыклардан ваз кичәргә чакыр,

www.darul-kutub.com

башыңа килгән бәлаләргә сабыр ит. Хактыр ки, болар Аллаһ фарыз кылган, рух ныклыгы таләп ителә торган нәрсәләрдер. Тәкәбберләнеп, кешеләрдән йөз чөермә. Дөньяда масаеп, борын чөеп йөрмә. Аллаһ кәпрәючеләрне, үзен генә сөючеләрне, мактанчыкларны сөймәс. Җәмгыятьтә табигый бул (адымың нык булсын),тавыш күтәреп сөйләшмә. Шуны онытма, дөньядагы иң ямьсез тавыш – ишәк тавышы», – диде («Локман» сүрәсе, 15-19 ны аятьләр).

Зур гөнаһларның да иң зурысы булган ширек катудан улын тыйганнан соң, Локман Хәким кечкенә гөнаһлардан да сакла違ырга куша. Пәйгамбәребез (с. г. в.) «Зур гөнаһлар кечкенә гөнаһ эченә, зур саваплар кечкенә савап эченә яшеренгән», – диде. Зур гөнаһ эшләсәк борчылабыз, шул ук вакытта кечкенә гөнаһка артык әһәмият бирмибез. Шуның нәтиҗәсендә аңа ияләнәбез, еш эшлибез. «Югары математика» дигән фәндә «Әгәр чиксез күп мәртәбә чиксез кечкенә әйберне кушсаң, чиксез зур әйбер килеп чыга» дигән төшенчә бар. Үкенеп тәүбә кылган һәм кабатланмаган зур гөнаһ, гөнаһ булудан туктый. «Берәү гөнаһларыннан тәүбә кылып, изге гамәлләр кыла башласа, Мин аның элекке гөнаһларын савапка алыштырам», – ди Аллаһ Раббыбыз («Фуркан» сүрәсе, 70 нче аять).

Зур гөнаһы өчен кайгырып йөрүче, кечкенә гөнаһны уйламаучы ике кешегә Локман Хәким эш куша. Берсенә 5 килограммлы бер таш алып килергә, икенчесенә 5 килограммлы вак таш җыярга. Алар бу эшне эшләгәч: «Инде урыннарына илтеп куегыз», – ди. Вак таш җыючы: «Мин урыннарын хәтерләмим, бу эш минем көчтән килми», – ди. Локман Хәким: «Кечкенә гөнаһлар шул ягы белән куркыныч, аларны хәтерләп һәм тәүбә кылып бетерергә мөмкин түгел, алар ахирәткә дә гөнаһ булып баралар», – ди.

Локман Хәкимнең хуҗасы да вак-төяк гөнаһларга салкын карый, исе китми. Яз җиткәч, хуҗасы бодай чәчәргә кушкан басуга Локман Хәким арпа чәчә. Игеннәр тишелеп чыгып үсә башлагач, хуҗа кеше басуга килә һәм: «Нишләп арпа чәчтең?» – дип сорый. «Борчылма, – ди. Локман Хәким – үскәч алар бодайга әйләнәчәк». «Җүләр, бу эш мөмкин түгел», – дигәч, «Дөнья

– ахирәтнең иген кыры, ни чәчсәң – шуны урасың. Син кечкенә гөнаһлар дип, гөнаһ чәчеп йөреп, нәрсә урмакчы буласың?» – дип җавап кайтара.

Пәйгамбәребез (с. г. в.): «Гамәл кылу – иген чәчү», – дигән. Әйдәгез, матур сүзләр сөйләп, матурлык таратыйк. Аллаһ дөньяны шулай яраткан, бар нәрсә бер-берсенә бәйле. Кайлардадыр зур җинаять, вәхшилек кылынганын күреп тетрәнәбез. Уйлап карасаң, анда да безнең сөйләгән начар сүзләрнең, кылган гөнаһларның (зурмы ул, кечкенәме) өлеше бар. Кайдадыр бер изгелек, игелек эшләнә икән, анда да безнең изге гамәлләребезнең өлеше бар. «Матурлык дөньяны коткарыр» дигән сүз дә шуннан. Әйдәгез, бер генә булса да агачмы, чәчәкме утыртып, бер-беребезгә сәлам биреп, бер-беребез турында матур сүзләр сөйләп, ачык чырай, көләч йөз белән йөреп, дөньяны коткаруда үзебездән өлеш кертик. Кешенең күңеленә мал белән түгел, көләч йөз, матур сүз, күркәм холык белән кереп урнашырга кирәк.

Әлбәттә, тәүбә кылгач аны кабатламау кирәк. Халыкта «тукран тәүбәсе» дигән төшенчә бар. Безне гөнаһтан саклый торган әйбер – вакытында җиренә җиткереп укылган намаз. Намаз безне гыйбадәткә, гыйбадәт күркәм холыкка алып бара. Локман Хәким дә улына Аллаһны таныгач, ширек катмаска чакыра, чөнки ширек иманнан чыгара. Аннан тәүбә кылырга, фарызларны үтәргә куша һәм гүзәл әхлакка чакыра. Тәүбә кылып күңелеңне чистартмыйча гыйбадәткә тотыну ул – күгәргән тимерне буяу кебек. Нинди генә матур, сыйфатлы буяу булмасын, нәтиҗәсе булмый – кубып төшә. Буяганчы яхшылап чистартырга кирәк. Бүген, мәчеткә йөреп, намаз укып та үз-үзебезне тиешенчә тота алмавыбыз – үзебезнең кимчелекләребезне күреп тәүбә кылмавыбызда. Кеше кимчелеген күреп, аны сөйләп кенә кеше булып булмый. Бер галим: «Мин кешенең хәрәм ашаганын җиңел беләм», – дигән. «Каян беләсең?» – дигәч: «Алар башкаларны хурлый, ямьсез сүзләр сөйли һәм зарлана», – дигән. Кимчелекле кешеләрне дә сүгәргә ярамый. Алар безгә үзебезнең кимчелекләрне төзәтер өчен җибәрелгән. Локман Хәкимгә «Ничек әдәпкә өйрәндең?» дигәч, «әдәпсезләрдән»

www.darul-kutub.com

дип җавап биргән. «Берәүдә ярамаган эш яки гадәт күрсәм, бу сыйфат миндә юк микән, дип, төзәлергә тырыштым», – дигән. Исерек бездә исерткечкә, гайбәтче гайбәткә нәфрәт уятырга тиеш. Без исерекне, гайбәтчене сүгәбез, шул ук вакытта үзебез исерткеч кулланабыз, гайбәт сөйлибез. Бу – хәрәм ашау һәм намаз укымау нәтиҗәсе. Гыйлемнең иң бөек ноктасы – әдәп. Пәйгамбәребез (с. г. в.): «Мин күркәм холык, әдәп урнаштырыр өчен җибәрелдем», – ди. Әдәпнең иң югары ноктасы үзеңне тыйнак, түбәнчелекле тоту, мактанмау. Локман Хәким улына масаюдан, кешеләрдән өстен куюдан, кычкырып сөйләшүдән тыелырга кушып нәсыйхәт бирә.

### 3. Локман Хәкимнең төрле китапларда искә алынган нәсыйхәтләре

Локман Хәкимнең Коръәни-Кәримдә улына биргән нәсыйхәтләре бәян ителде, алга таба төрле китаплардагы, риваятьләрдәге, хикәятләрдәге нәсыйхәтләре искә алыныр. Ул мең ел яшәгән, күп киңәшләр биргән, бигрәк тә сигез төрле эшкә игътибар итәргә кушкан. Ике хакыйкатьне беркайчан да онытмаска. Беренчесе – Аллаһ Тәгалә. Ул бар, бер, бар нәрсәдән өстен, бар нәрсәне ишетеп, күреп, белеп тора, шуңа тормышыңны Ул риза булырлык итеп алып барырга, Ул кушканнарны үтәргә, тыйганнарыннан тыелырга. Икенчесе – үлем. Ул һичшиксез киләчәк, аңа әзер булырга. Үлем сәгате килгәндә кылган изгелекләрең гөнаһларыңнан күп булсын. Үлем хак булган кебек, үлгәннән соң терелү дә хак. Аллаһ каршында җавап тотканда йөзең кызарырлык эшләр эшләмәскә кирәк. Ике әйберне исеңдә тотма, оныт. Беренчесе – кемгә генә яхшылык кылсаң да, аны хәтереңдә тотма. Эшләгән яхшылыгың өчен башкалардан нәрсәдер өмет итү – ул эшнең Аллаһ ризалыгы өчен эшләнмәвен күрсәтә, ахирәттә әҗерен югалтуың бар. Кемдер сиңа начарлык кылса, аны да оныт, сөйләп йөрсәң, начарлык таратучы булырсың һәм авыруга сабышырсың. Истә тоткан начарлык истә тотучыга, онытылган начарлык эшләүчесенә зыян китерә.

Дүрт әйберне сакла. Беренчесе – күңелеңне намазда сакла, намазлыктан чыгып китмәсен; икенчесе – ашказаныңны артык ризыктан сакла. «Ашагыз, эчегез, ләкин исраф кылмагыз. Аллаһ исрафчыларны сөйми» («Әгъраф» сүрәсе, 31 нче аять). «Сез тутырган капчыкларның иң хәерсезе – ашказаны» (Хәдис). Күзеңне кирәкмәгән нәрсәләрне караудан, телеңне кирәкмәгән сүзләр сөйләүдән сакла.

Дүрт ай да ун көндә ана карынындагы балага ашыйсы ризыгы, килә торган дәүләте язып куела. Аңа барыбыз да ышанабыз. Әмма аңлап бетермибез. Димәк, барлык куллана торган әйберләребезнең дә чиге (лимиты) куелган. Нәфесеңне җиңеп, саклап тотсаң, исраф кылмасаң, ул озакка җитә. Бездә кемдер урынга яки дәрәҗәгә күтәрелсә, иң актив кулланучыга әйләнә. Барысы да башкаларныкыннан артыграк, күбрәк булсын. Урыныннан китәргә мәҗбүр булгач, кемгәдер үпкәләп, ачу саклап йөри. Ник үпкәлисең? Лимитың беткән. Вак-вак кабып, чамалап кына ашарга иде. Комсызланып кабабыз да, тыгылгач кемне дә булса гаеплибез. Уртача булырга, чаманы югалтмаска кирәк. Халыкта: «Күп ашасаң, аз ашарсың», – дигән әйтем бар. Югарыда китерелгән Коръән аятендә сүз ризык турында гына бармый, ул барлык мал-мөлкәткә дә кагыла.

Локман хәкимгә хуҗасы: «Бер сарык суеп, иң тәмле җиреннән ике кисәк алып, пешереп кил», – диде. Локман Хәким сарыкның теле белән йөрәген пешереп алып килде. Берничә көннән соң: «Йә, Локман, куйның иң тәмсез әгъзасыннан ике кисәк ит пешереп алып кил», – диде. Локман Хәким янә йөрәк белән тел пешереп алып килде. Хуҗасы: «Ләззәтле әгъзасыннан дисәм дә, тәмсез әгъзасыннан дисәм дә тел белән йөрәк пешереп алып килдең, ни өчен алай иттең?» – диде. «Йә, хуҗам, хайванның я кешенең теле белән йөрәге яхшы булса, үзе дә яхшы булыр, әмма йөрәге белән теле яман булса – үзе дә яман булыр», – диде.

Күңелдә нинди агач үссә, телдә шул агачның җимешләре. Күңелендә ямьсезлек агачы булган кеше башкалар турында яхшы итеп уйлый да, сөйли дә, аларны бәяли дә белми. Юньсезлек акылын да ала. Акылы булса, үзенә карап башкаларга бәя биргәнен аңлар иде. Пәйгамбәребез (с. г. в.) сәхабәләр

www.darul-kutub.com

белән утырганда Әбу Бәкер (р. г.) килеп керде һәм әйтте: «Йә, Рәсүлүллаһ, син нинди күркәм, синнән нур бөркелә, син кешеләргә изгелек, матурлык таратасың», – диде. «Хак әйтәсең», – диде Пәйгамбәребез (с. г. в.). Бераздан кара көеп бер кеше керде һәм кычкырды: «Йә, Мөхәммәд, син нинди юньсез кеше, син начарлык таратасың, кешеләр арасын бозасың», – диде. «Хак сөйлисең», – диде Рәсүлүллаһ (с. г. в.). Сәхабәләр аптырашып: «Ничек инде син икесенә дә бер төрле җавап бирдең?» – дигәч, Пәйгамбәребез (с. г. в.) елмаеп: «Алар бит икесе дә миңа түгел, үзләренә бәя бирде, кешенең эче нинди – сүзе шундый. Әбу Бәкер – саф күңелле изге кеше, ул башкаларда да шуны күрә. Ә теге кеше ул гомере буе кешеләрне дошманлаштырып, сугыштырып, шуннан тәм табып яшәүче, башкаларда да үзендә булган сыйфатларны күрә», – диде.

Кодси хәдистә Пәйгамбәребез (с. г. в.): «Аллаһ күкләргә, җирләргә сыймады, әмма иманлы кешенең йөрәгенә (күңеленә) сыя», – диде.

Аллаһ безнең байлыгыбызга да, дәрәҗәбезгә дә түгел, күңелебезгә карый. Кешенең күңеле чиста булган саен Аллаһ каршында дәрәҗәсе арта, догасы да куәтлерәк була. Байлык, күпме генә булса да, әгәр күңелеңдә булмаса, куркыныч түгел. Үзең ярлы булып та, күңелеңдә Аллаһ урынында байлык булса – ул да әйбәт түгел. Ярлы дигән сүз – тәкъва дигән сүз түгел.

Аллаһның рәхмәте белән Локман Хәким бик күп тәҗрибә туплаган, бик күп нәсыйхәтләр әйткән, аны язып бетерү мөмкин түгел, менә аларның кайберләре:

– Сәүдәң уңышлы булсын дисәң, сәүдәдә гадел бул, табыш һәрчак килеп торыр. «Үлчәүдә хыянәт кылган тормышында авырлык күрер» (Хәдис). Тапкан табышыңнан ятимнәрне, мохтаҗларны сөендерергә онытма. Дөнья малы хисабына җәннәтне кәсеп итү – нинди уңышлы сәүдә, вакытлы байлыкны мәңгелек сәгадәткә алыштырасың.

– Җеназаларга катнаш, каберләрне зиярәт кыл, бар нәрсә дә вакытлы, бар нәрсә дә үтә. «Бар вәгазь кешенеке, үлем – Аллаһның вәгазе» (Хәдис). Аллаһның вәгазе белән вәгазьлән. Кабердә байлыктан сөенеч юк, изге гамәлләр генә сөенеч бирә.

www.darulkutub.com

– Күңел ачуларга күп йөрмә. Күп күңел ачу – күңелне үтерә – Аллаһны онытуың һәм җиңел яшәргә теләгең уянуы бар.

– Байлар янына сирәгрәк йөр – үз тормышыңа канәгатьсезлек, аларга карата көнчелек уяунуы бар.

– Мохтаҗларның, авыруларның хәлен еш бел – шөкрана хисең артыр. Параличланган кеше бер сәҗдәдә маңгаен җиргә тидерер өчен, бер мәртәбә мәчеткә барыр өчен бар байлыгын бирер иде. Сукыр кеше Коръәнне ачып укыр өчен бернәрсәсен дә кызганмас иде. Сәламәт кешеләргә бу эшләрне эшләр өчен бер тиен дә кирәк түгел – ник кадерен белмибез? Бер көн килер – соң булыр…

– Таңда әтәч кычкыргач, йокыңнан тор, намазыңны укып хәләл кәсепкә кереш. Әтәчтән дә ялкау булма. «Сезнең хәерлегез – дөньясы дип ахирәтне куймас, ахирәте дип дөньясын куймас, икесен дә тигез күрер, һәм башкаларга йөк булмас» (Хәдис).

– Тәүбәңне икенче көнгә калдырма – үлем кайчан киләсен белмисең. Гөнаһлы кешенең гөнаһы – гөнаһ кылганнан соң тәүбә кыйлмыйча, тәүбәсен кичектерүдә. Үлем килгәч тәүбә капкасы ябыла.

– Әдәпле, хикмәтле, тәкъва галимнәр белән аралаш, аларны тыңла. Чиста күңелле кешеләр белән аралашу, аларны тыңлау – яңгыр коры җирне терелткән кебек күңелеңне терелтер. Хикмәтне кайдан тапсаң – шуннан ал, хикмәт ярлы кешене дә патшалар белән аралаштыра.

– Белгән гыйлемнәреңне тормышта дөрес итеп кулланырга өйрәнмичә, яңа гыйлем артыннан чапма. «Гыйлеме булып та, аны куллана белмәгән кеше – китап төягән ишәккә охшаш» (Хәдис). Ишәк өстендә китап күбәюдән берәүгә дә файда юк, ишәкнең йөге генә арта.

– Дөнья ул – диңгез. Бик күпләр анда батып үлде. Исән каласың килсә, тәкъвалык, канәгатьлек көймәсенә утыр. Дөнья белән ахирәт – ике бертуган кызлар кебек. Икесенә берьюлы никахланып булмый. Берсе белән бәхетле булыйм дисәң, икенчесеннән ваз кичәргә кирәк.

www.darul-kutub.com

– Аллаһны искә алучылар, Аллаһ турында сөйләүчеләрне ишетсәң – ул җирдән китмә. Аллаһ аларга рәхмәт күзе белән караганда, сиңа да өлеш чыгар.

– Буш сүз, гайбәт сөйләүчеләр янында торма, күңелең каралыр, тупасланыр, изге гамәлләрең юкка чыгар. Аларга Аллаһның газабы килгәндә сиңа да өлеш чыгар. Сүзеңне өч иләк арасыннан үткәреп кенә әйтү кирәк. Беренчесе – дөреслек иләге, әйтәсе сүзең дөресме? Телнең иң зур афәте – ялган. Икенчесе – файда иләге, әйткән сүзеңнең берәр кешегә файдасы бармы? Өченчесе – матурлык иләге, әйтәсе сүзең матурмы?

– Ризыгыңны тәкъва кешеләр белән бүлеш. Синең ризыгыңны ашагач, алар изге гамәлләр кылыр, сиңа да өлеш чыгар.

– Эшеңне тәкъва, хикмәтле, тәҗрибәле кешеләр белән киңәшләшеп эшлә һәм Аллаһка тәвәккәл кыл.

– Телеңне истигъфарга гадәтләндер. «Әстәгъфируллаһ, Әллааһүммәгъфирли»ләрне еш әйт. «Көнгә ким дигәндә 70–100 мәртәбә истигъфар әйтегез» (Хәдис).

– Озак яшәдем, күп йөкләр күтәрдем. Хәерчелек йөгеннән дә авыр йөк күрмәдем. Кирәксә-кирәкмәскә бурыч алудан саклан. Бурыч ул – көндезләрен кимсенү, төннәрен – авыр уйлар. Күпләр, барына канәгать булмыйча, баю нияте белән бурыч (кредит) алып, хәерчелек җимешләрен татый. *(Бер әби базарда дару үләннәре сата икән. Бер сатып алучы: «Боларның файдасы бармы?» – дип сораган. Әби: «Нишләп булмасын, узган ел малайга машина алдык, быел кияүгә алырга җыенабыз», – дигән.)* Шуның кебек, кредитның да файдасы бирүчегә генә. Аллаһ Раббыбыз да аны хәрәм кылган.

– Бар нәрсәне онытып дөнья кума, бервакыт дөнья сине куар. Мөмкинлегең булып та, хәләл кәсебеңне ташлама, ялкаулык тәкъвалыкка керми. «Кеше ашаган ризыкның иң хәерлесе һәм иң файдалысы – маңгай тирен түгеп тапканы» (Хәдис).

Тормышыңны Аллаһ кушканча алып бару, хәләл кәсеп белән шөгыльләнү – кояшка таба бару кебек. Ул очракта дөнья күләгә кебек, синең артыңнан бара, борчылма, бер кая да китми. Гамәл-гыйбадәтсез, хәрәм юл белән дөнья куу – кояшка арка-

ны куеп бару кебек. Ул очракта күләгә алдан бара, нинди генә тизлек җыйсаң да, куып тота алмыйсың, хәлең бетеп егылуың гына мөмкин. Әле җитмәсә җәннәтне дөнья малына алыштырып, җәһәннәмне кәсеп итәсең. Моннан да уңышсыз, мәгънәсез сәүдә буламы?

– Гыйлем алсаң, ахмаклар белән бәхәсләшер өчен, кешеләр арасында дан казаныр өчен генә алма. Барысын да белеп, күреп торучы Аллаһ бар. Аның каршысына баскач кыен хәлгә калуың бар. Бар кешене дә алдап була, Аллаһны гына алдап булмый.

– Ахмакларга нәсыйхәт биреп вакытыңны үткәрмә. Бер нәсыйхәт биргәч – ахмак икәнен аңласаң, дәшмәү булыр нәсыйхәтең.

*Гайсә (г-м) чаба икән: «Нәрсәдән куркып чабасың?» дигәч, «ахмактан» дип җавап биргән. «Син күзсезләрне күзле итүче, авыруларны терелтүче, ни өчен ахмактан курыктың?» – дигәч: «Әйе, мин Аллаһның рәхмәте белән, Исме Әгъзәм догасы укып күзсезләрне күзле иттем, күп авыруларны терелттем, чөнки алар авыруларын белә, дәвалану өчен Аллаһтан сәбәп эзли иде. Ахмак ул – үзен галим дип санаучы надан, үзенең кимчелеген белми дә, күрми дә, аңа ничек ярдәм итеп булсын, зыянын сала күрмәсен дип качам», – дигән.*

Авыру – гөнаһларын танып, үкенеп тәүбә кылучыларга гөнаһларыннан арыну өчен бирелгән Аллаһның нигъмәте, алар дөньялыкта ук тилмерә, сабыр итүчеләрне җәннәткә алып бара. Ахмаклык – тәкәбберләргә бирелгән Аллаһның ләгънәте. Алар үз кимчелекләрен күрә, төзәлә алмый, башкаларның юк кына кимчелекләрен купайтып сөйләп, тирә-яктагыларны тилмертә. Мисалы – Адәм (г. с.) нәфесенә кереп хаталанды, тәүбә кылды. Иблис тәкәбберләнеп гөнаһ кылды, бүгенге көнгә кадәр тәүбә кыла алмый, кешеләргә зыян китерә, югыйсә гыйлеме дә җитәрлек, Аллаһны да күргән. Гыйлем чиста күңелле кешегә генә файда китерә, ягъни файдалы гыйлем була. Моның мисалы татар халкының фикер иясе, мәгърифәтче Каюм Насыйриның «Әбугалисина» әсәрендәге баш геройларында күренә. Әбугалисина белән Әбелхарис икесе дә бер үк мәгарәдә, бер үк

www.darul-kutub.com

китаплардан бер ел буе гыйлем ала. Әбугалисина кешеләргә яхшылык кылучы (олуг галим, зыялы) булып җитешә, ә Әбелхарис начарлык юлына керешеп китә.

Әбу Ләһәбләр, Әбу Җәһилләр дә хәтта пәйгамбәребезне (с. г. в.) күрде, аның вәгазь-нәсыйхәтләрен ишетте, тәкәбберлекләрен җиңеп, үзләрен үзгәртә алмады. Бүген мәчеткә йөрмәүче күп кенә кешеләр имамнарны гаепли. Күңелеңдә тәкәбберлек чире булса, пәйгамбәр дә ярдәм итә алмый. Андый кешеләр турында Аллаһ Раббыбыз Коръәни-Кәримдә («Бәкара (Сыер)» сүрәсенең 171 нче аяте): «Суммүм бүкмүн гүмйүң фәһүм ләә йәгкыйлүүүн», – диде, ягъни «Алар чукрак, телсез кебек (хакыйкатьне ишетмәс, күрмәс). Шуңа күрә аларның башы уйлар дәрәҗәдә түгел».

– Яхшы кешеләр янында үзеңне түбәнчелекле тот. Су чокырга җыелган кебек, хикмәтне дә Аллаһ үзен түбәнчелекле тотучыларга бирә.

– Юньсезләр белән дуслашма. Черек алма янына бер түгел, бер дистә яхшы алма куйсаң да, ул яхшырмый, яхшылары бозылырга мөмкин.

*Су буенда чаян елап утыра икән. Ташбака, аның елавының сәбәбен сорагач: «Йөзә белмим, су аркылы чыга алмыйм», – дигән. Ташбака чаянга яхшылык эшләмәк булып, аны аркасына утырткан һәм суга кереп киткән. Елга уртасында тык-тык иткән тавыш ишетеп, чаяннан сораган: «Син нишлисең?» Чаян: «Сине чагарга тырышам, булдыра алмыйм, кабыгың комачаулый», – дигән. Ташбака: «Мин сиңа яхшылык эшлим, ә син ни өчен мине чагарга телисең?» – дигән. «Мин башкача булдыра алмыйм», – дигән чаян. Шуннан соң ташбака, башкаларга зыян салмасын дип, чаянны елга уртасында ташлап калдырган.*

– Үткәннәргә үкенеп гомереңне үткәрмә, кулыңнан ычкынганны кайтарам, дип азапланма. Сиңа насыйп – сиңа, сиңа насыйп булмаганны куып тота алмыйсың. Үзеңә бирелгәнне кулыңнан ычкындырма, шөкер ит. Күп вакыт кулыбыздагының, яныбыздагының кадерен белмибез, югалткач – үкенеп елыйбыз. Исән чакта, бергә чакта бер-беребезнең кадерен белик. «Үлем

www.darul-kutub.com

килүдән элек – яшәвеңне, картлык килүдән элек – яшьлегеңне, ярлылык килүдән элек – байлыгыңны, мәшәкатьтән элек буш вакытыңны Аллаһтан ганимат дип бел» (Хәдис).

– Балаларыңның сөенечен күрим дисәң, аларны игелек кылудан тәм табарга өйрәт. «Әти-әнинең балага калдырган иң зур мирасы – яхшы тәрбия» (Хәдис). Байлык белән генә бала тәрбияләп булмый, вакытыңны да бирергә кирәк, нәтиҗәсе күбрәк булыр. *(Бер бала әтисеннән: «Әтием, син көненә ничә сум акча эшлисең?» – дип сораган. Әтисе: «Биш йөз сум», – дип җавап биргән. Көннәрдән беркөнне әлеге бала әтисеннән ике йөз сум акча сораган. Әтисе: «Ул сиңа нәрсә өчен кирәк?» – дигән. Бала кеше: «Мин тырышып өч йөз сум акча җыйдым, син ике йөз сум бирсәң, биш йөз сум була. Шул акчаны сиңа бирер идем дә, бер көн буе минем белән булуыңны теләр идем», – дигән.)* Тәрбия кылганда балаларга тиешле шелтә бирү, күпмедер җәза бирү (наказание) – корылык вакытындагы яңгыр кебек үк кирәк.

– Юлга чыксаң, әзерләнеп, кирәкле әйберләреңне җыеп чык (тиешле кием, энә-җеп, савыт-саба, дарулар, бераз ризык). Үзеңә кирәк булмаса, иптәшләреңә кирәк булуы бар. Иң элек яхшы иптәш тап. Кайвакыт юлда туктап каласың, су яки бензин алыйм дисәң – чиләк, казып чыгарыйм дисәң – көрәк, тарттырыйм дисәң – бау булмый. Аптечканы да юл инспекторларына күрсәтү өчен генә йөртәбез, югыйсә ул аларга түгел, безгә кирәк.

– Гел йөзеңне чытып, зарланып йөрмә. Син зарланганга, кайгыңны сөйләгәнгә дусларың (якыннарың) борчылыр, ә аларны нигә борчырга? Дошманнарың сөенер, ә аларны нигә сөендерергә? Ләкин күпме генә зарлансаң да, хәсрәтең дә, авыруың да кимемәс. Шат күңелле, ачык йөзле бул, барына канәгать бул – бәхетле тормыш кичерерсең.

– Кеше кулындагыга кызыкма. Кирәк әйберне иң элек Аллаһтан сора. Ул бер хәерле бәндәсе аркылы сиңа сәбәбен чыгарыр һәм син сөенеч табарсың, теләгеңә ирешерсең.

– Теләгең кабул булмаса – кайгырма. Кайвакыт теләк кабул булмау кабул булудан хәерле була. Безгә нәрсә кирәген без белмибез. Аллаһ – белүче. *Бер елан биетүче елан сатып*

*алган, кичтән еланын урлаганнар. Еланым табылсын иде дип, төне буе дога кылган. Иртән ишетә – бер каракны елан чагып үтергән. Елан биетүчегә, алдап, чага торган елан саткан булганнар. Шуннан куанып: «И Раббым, рәхмәт Сиңа, әле дә ярый без җүләрләрнең бар теләген дә кабул итмисең», – ди икән.*

– Яхшылыкны да тиешле кешесенә эшлә. Аның белән файдалана белмәүчегә эшләсәң – яхшылыгың әрәм булыр, юкка чыгар. Бу дөньяда да югалтуга дучар булырсың, ахирәттә дә әҗерен күрмәссең. Төпсез кисмәккә су тутырган кебек.

– Саран да булма, исраф та кылма – үзеңне яхшы хис итәрсең. «Һәр исраф – хәрәм» (Хәдис). Тиешле урынга мал сарыф итү, сәдака бирү – исраф түгел, шлангадан су сибү кебек. «Су әзрәк китсен», – дип шланганы кыссаң, суның килүе дә кими.

Әйтәләр ки, Локман Хәким улына бер капчык гәрчич орлыгы санынча нәсыйхәт кылган. Аларны санап-язып бетерү мөмкин түгел. Монда аларның кайберләре. Һәркайсыбызга дөрес нәтиҗә ясарга, хаталардан сакланырга ярдәм итсә иде.

## 4. Локман Хәким турында хикәятләр

* * *

Локман Хәкимнең ике хатыны булган. Берсенең – күзе, икенчесенең аягы зәгыйфь икән. «Син акыл иясе, ни өчен кимчелекле хатын алдың?» – дигән сорауга: «Хатын-кыз ирдән күркәмлектә, байлыкта, нәселдә – кимрәк, тәкъвалыкта артыграк булса хәерле. Күп вакыт чибәр хатын иргә түгел, ир аңа хезмәт итә, ир хатын колына әйләнә», – дип җавап биргән. Тарихка күз салсак та, дөньяларын тетрәткән падишаһлар чибәр хатыннары аркасында харап булган: Атилла, Александр Македонский һ. б. Төркиянең данлыклы Сөләйман патшасы да хатыны Роксалана алдында көчсез булган.

Акыллы кеше хатынны байлыгына, чибәрлегенә карап түгел, акылына, әдәбенә, тәкъвалыгына карап сайлый.

www.darul-kutub.com

* * *

Локман Хәким ерак сәфәргә китәр алдыннан улына нәсыйхәт кылып әйткән. Диңгез, ут, хатын-кыз – бер төрле. Алардан башка яшәү дә авыр, аларның нәрсә китереп чыгарасын да белеп булмый. Диңгезгә ышанычлы көймә белән кер, ут белән сак эш ит. Байлар, җитәкчеләр дә ут кебек, бик якынайма – янарсың, бик ерагайма – туңарсың. Сереңне хатыныңа сөйләмә.

Тормыш нужасы күрмичә, маңгай тире түкмичә генә кисәк баеган яңа байдан әҗәткә алма. Туган җиренә маңгай тире таммаган кешегә туган җире кадерле булмый. Кисәк кенә баеган яки күтәрелгән кеше (халыкта аны «бөреләнми генә чәчәк аткан» диләр) башкаларның хәлен аңлый белми. Бүген күп байларыбызның халык мәнфәгатен кайгыртмавы, акчаларын чит илләргә җибәрүе – шуның нәтиҗәсе. Алар өчен ил дә, халык та юк, акча һәм нәфес кенә бар. Андыйларны Аллаһ Раббыбыз күңел тынычлыгыннан һәм гаилә бәхетеннән, халык мәхәббәтеннән мәхрүм итә.

Ялагай һәм куштан кеше белән дуслашма. Андый кешегә караганда, дошман яхшырак. Чөнки дошман уйлаганын йөзеңә бәреп әйтә, икейөзлеләнми. Аннан нәрсә көтәсен дә белеп торасың, аның белән сак эш итәсең. Кытай халык мәкале дә әйтә бит: «Дошманыңны җиңә алмасаң, аның белән дуслаш, шул чакта гына аңа рәхәтләнеп зыян сала аласың». Сине күралмаучылар, тәнкыйтьләүчеләр дә – Аллаһның рәхмәте. Ачы дару сихәт биргән кебек, алар сиңа кимчелекләреңне күрергә, үз өстеңдә эшләргә, яхшырак булырга, алга барырга ярдәм итә. Ялагай – сазлык кебек, сиңа каршылык күрсәтми, әмма сине төпкә сөйри. «Ялагайларның йөзенә көл сибегез» (Хәдис).

Әтисе киткәч, улы аның сүзләрен сынап карамакчы була. Шәһәр башлыгының бер куштаны белән дуслаша, яңа байдан әҗәт ала, бер сарык суеп пешереп, капчыгына тутырып өенә алып кайта. Хатыны капчыкта нәрсә барлыгы белән кызыксынгач: «Әй минем сөекле хатыным, сахрада берәү белән ачуланыштык, үтереп котылдым – югыйсә мине үтерә иде, зинһар, берәүгә дә сөйләмә, сиңа гына әйтәм», – ди. Көннәрдән беркөнне

хатыны белән сүзгә килделәр. Хатыны әйтте: «Үзеңне бел, мин дигәнчә булмаса, үзеңне зинданга яптырам». Ире ачуланган булып хатынына сукты, шуннан хатыны өйдән йөгереп чыгып, каравыл кычкырды: «Минем ирем фәлән көнне берәүне үтерде, бүген мине үтермәкче була, коткарыгыз!» Халык җыелды, бу хәбәр шәһәр башлыгына иреште. «Локман Хәкимнең улын зинданга ябыйк, кем алып килә?» – диде ул. Теге куштан дусты: «Үзем алып киләм, мин аны беләм», – дип, Локман Хәким улын алырга сакчылар белән килде. Ул ялварды: «Син бит минем якын дустым, бу баладән качарга ярдәм ит», – диде. Дусты тыңламады, кулларын бәйләтеп алып китте. Моны ишеткән яңа бай тиз килеп җитте: «Тизрәк минем алачагымны бир», – диде. «Хәлем авыр, күрмисеңмени, бераз көтеп тор», – дигәч, ризалашмады, «өеңне яздыртам», дип куркытты. Локман Хәкимнең улы әҗәтен кайтарды.

Шәһәр башлыгы янына алып килгәч, шәһәр башлыгы: «Әй, хөрмәтле кешенең улы, гаҗәп эш кылдың. Сиңа килешми, хөкем итеп җәзага тартабыз», – диде. Локман Хәкимнең улы әйтте: «Үлгән кешенең никадәр җәрәхәте булса, мине дә аннан артык җәрәхәт кылмый үтерегез», – диде. Хатыны сөенә-сөенә капчык яшерелгән урынны күрсәтте. Капчыкны шәһәр башлыгы янына алып килделәр, ачып карасалар – пешкән сарык ите. «Бу ни хәл?» дип сорадылар. Локман Хәкимнең улы әтисенең нәсыйхәтләрен тәҗрибә кылып каравын әйтте. Бу күпләр өчен сабак булды.

* * *

Локман Хәким кол вакытта хуҗасы аны бакчасына җимеш җыярга җибәрә. Барлык коллар күп итеп җимеш ашый, ләкин Локман Хәким ашамый. Рөхсәтсез ашаган җимеш хәрәм була, калебне каралта, ихтыяр көчен бетерә. Мәрхүм Габделхак хәзрәт Саматовның (урыны җәннәттә булсын) сүзләре искә төшә. «Бөтен җирләрне, атларны алып колхоз төзеделәр, ашарга бирмәделәр. Шулай итеп халыкны урлап ашарга, хәрәм ашарга өйрәттеләр. Аннан инде аракы эчү, зина кылу гадәткә әйләнде».

www.darul-kutub.com

Әни сөйләгәннән. Сугыш башлангач әнинең әбисе янына авыл карчыклары җыела. Әнинең әбисе – Гөлбикә әби – укымышлы кеше була. «Балалар ачтан шешенә, ризык юк, колхозныкын урласак, хәрәм булмыймы?» – дип сорыйлар.

Гөлбикә әби: «Җирләребез шунда, атларыбыз шунда, ирләрегез сугышта, балаларыгызны ачтан тилмертмәгез, урлавыгыз бу очракта хәрәм булмас», – ди. Ул вакыттагы халыкның әхлагын карагыз, алар намаз укучылар булган. Бүген ач булмасак та, «әйдә, колхозныкы бит әле, хуҗасы күрми әле» дип, кирәкме-түгелме, нәрсәдер эләктерергә тырышабыз. Үзебезгә дә, балаларга да хәрәм керә. Бер елны колхоз басуында бәрәңге чүпләгәндә бар бала да чиләгенә бәрәңге салып кайта икән. Намаз укучы кызның чиләге буш. Барысы да аңа юләргә караган шикелле караган, гаепләп сөйләгән. Күмәк милек, күмәк хезмәт дип, әхлак дәрәҗәсен нинди «биеклеккә» күтәрдек. Күп вакыт хуҗалар гади халыкка күмәк миллекне ничек итеп, күпме итеп үзләштереп булуның даһи үрнәкләрен күрсәтә. Аннары зур трибуналардан «караклык начар» дип сөйләүдән ни файда? Аллаһ барын да күреп тора, халык та юләр түгел.

Юләрләр арасында бер акыллы булса, юләрләр аны диванага чыгарып көлә. Төрекмән язучысы Мәхдүмколый да бит: «Ишәкләр янында ишәк кебек бул, чын йөзеңне ачма», – дигән. Коллар да Локман Хәкимнән көлгән һәм кайткач сүз берләшеп: «Ул җимеш ашады», – дип хуҗага җиткергән. Бар шаһитлар да Локман Хәкимгә каршы. Хуҗасы ачуланып: «Сиңа нинди җәза бирим?» – дигәч, Локман Хәким: «Син барыбызга да күп итеп җылы су эчер, аннан йөгерергә мәҗбүр ит, хакыйкатьне күрерсең», – дигән. Күп итеп җимеш ашаучыларның барысы да йөгергәндә коскан, Локман Хәкимнең генә су чыккан. Хуҗа эшнең ни икәнен аңлаган. Локман Хәким зарланмаган, әләкләмәгән, хәтта акланмаган да, үзенең зирәклеге белән кыен хәлдән чыккан.

* * *

Бервакыт, каядыр баргач, Локман Хәкимне тышта калдырып, хуҗасы бәдрәфкә кереп китә һәм озак тора. Локман Хәким

хуҗасы өчен борчылып: «Бәдрәфтә озак тору – бавыр авыртуы, кан басымы күтәрелү, геморрой кебек чирләргә сәбәпче», – дип кисәтә. Хуҗасы бу сүзләрдән шулкадәр тәэсирләнә, бәдрәф ишегенә язып куярга куша – башкалар да белсен өчен.

Без кайда гына булса та, кем булуына карамастан, кешеләрне яхшылыкка өндәргә, аларга зыян сала торган эшләрдән кисәтергә тиеш. Безгә 70 ел буе бай кеше – начар кеше дип өйрәттеләр – хәләл кәсеп белән баеган, кешеләрне эш урыны белән тәэмин иткән, яхшы яшәргә мөмкинлекләр тудырган, зәкят-гошерләре белән мәчет-мәдрәсәләрне тоткан, ятимнәргә, мохтаҗларга ярдәм итүче кешеләр начар булмый. Шуңа күрә дә ислам кәсепне һәм сәүдәне тыймый, хуплый гына. Яхшы хезмәтче хуҗасының сәламәтлеген дә, мал-мөлкәтенең иминлеген дә, артуын да кайгыртырга тиеш. Яхшы хуҗа да хезмәтчесенә карата гадел булырга, хезмәтен гадел бәяләргә, вакытында тиешенчә хезмәт хакын түләргә бурычлы. Бушка  буш эш эшләтеп кенә була. Эшләүчеләр эш урыннарыннан кәнагать булырга һәм эш урыннарын югалтудан куркырга тиеш. Шул вакыт кына нәтиҗәле эш таләп итеп була. Бүген авыл хуҗалыгы продукциясенә тиешле бәя булмау, җитештерүчеләрнең тиешле хезмәт хакы ала алмаулары авыл хуҗалыгы үсешен тоткарлый, җитештерү кими. Файдалы кредит булмаган кебек, чит илләрдә дә очсыз продукция юк. Булса да, үзебезнекен юкка чыгарганчы гына. 2010 нчы елны корылык булды, бәрәңге булмады, берәү дә чит илдән өч сумга бәрәңге кертмәде. Халык җитештерүне кайгыртсын өчен, хөкүмәт халыкны кайгыртырга тиеш.

Айга менмәгән, ракеталары булмаган ил яши дә, бәйсез дә була ала. Әмма үзен ризык белән тәэмин итә алмаган ил бәйсез була алмый. Ил иминлеге өчен дип коралга акча тотыла, ләкин шул ук вакытта авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүгә җитәрлек акча бүленми. Югыйсә, ул да бит илнең иминлеген тәэмин итә.

* * *

Локман Хәким Дауд (г-м) янына килгән. Дауд (г-м) тимерчелектә тимердән вак боҗралар ясау белән мәшгуль икән.

www.darul-kutub.com

Локман Хәким сәлам биреп килеп утырган, карап тора башлаган, «нәрсә ясыйсың?» дип сорамаган. Дауд (г-м) бөҗраларны бер-берсенә тоташтыра башлаган, сугыш киеме – көбә күлмәк килеп чыккан. Сокланып, «Нинди нык күлмәк чыкты, хуҗасын дошман угыннан, кылычыннан саклар инде», – дигән.

Локман Хәким:

– Сабырлыгым аркасында сорау бирми дә эшеңнең нәтиҗәсен күрдем. Тәкъдиремне исемә төшердем. Тормышта бер-берсенә бәйләнмәгән күпме вакыйгалар була. Кайберенә борчылабыз, бәргәләнәбез, сабыр итә белмибез. Безгә язган бездән беркая да китми, менә шушы күлмәк кебек – безнең өстә. Һәр эш Аллаһның тәкъдире белән. Бер-берсенә бәйләнгәч, тормыш була. Тормыш әнә шул бөҗралар кебек ваклыклардан тора, вакланмасаң, бербөтен гүзәл кием кебек була. Вакланмыйча сабыр иткәннәр генә матур нәтиҗәсен күрә.

Һөнәр – нинди зур байлык, эштән ләззәт таба белү – нинди бәхет, сабырлык исә күркәм нәтиҗәләргә китерә, – дигән.

Без берәүнең нәрсәдер эшләгәнен күрсәк, «Ни эшлисең?» дип сорап, аны эштән бүләбез, акыл өйрәтә башлыйбыз, үпкәләтәбез. Балаларыбызны «кирәкмәгән эш эшлисең» дип сүгәбез, эшкә өйрәтергә сабырлыгыбыз җитми. Балаларыбыз эштән бизеп, сабырсыз булып үсә. Укытып кына кеше ясамакчы булабыз. Сугышның башыннан ахырына кадәр төрле лагерьларда немец әсирлегендә булган Котдус абыйның (урыны җәннәттә булсын): «Нигездә, һөнәрле кешеләр исән калды», – дип сөйләгәне бар.

Балаларыбызны «Яхшы укыгыз, югыйсә авылда калырсыз» дип куркытып, эш кешеләрен, һөнәр ияләрен кимчелекле кешеләр итеп күрсәтәбез, эшкә өйрәтмибез. Бүген бу – иң зур кимчелегебез. Дауд (г-м) – пәйгамбәр булган, патша булган, моның өстенә оста тимерче дә булган.

Эш белмәгән, эш рәтен белмәгән, тормышны күрмәгән, маңгай тирен түгеп бер кисәк ризык капмаган кеше ничек итеп башкаларның хезмәтен бәяли белсен һәм хезмәт кешесенең кадерен белсен. Матди байлыкны урында утыручылар түгел, һөнәр ияләре – эшчеләр, игенчеләр, терлекчеләр тудыра. Аларның

хезмәтләрен тиешенчә бәяли, аларга хезмәт итәргә тиешле шартлар тудырмый торып, бер ил дә алга бармаячак.

* * *

Локман Хәкимнең бер дусты булган, Локман Хәкимне шулкадәр хөрмәт иткән, ризыгын да иң элек аңа тәкъдим иткән. Бервакыт аңа кавын бүләк иткәннәр. Ул кавынны кисеп Локман Хәкимгә биргән, Локман Хәким бик тәмләп ашый башлаган. Аңа кызыгып дустының да ашый башлавы булган, кавын авызга алгысыз ачы булган. Гаҗәпләнеп: «Ни өчен ачы дип зарланмадың?» – дигән. «Мин кавынга түгел, бирүче кулга игътибар иттем. Чын дус кулында ачы әйбер дә татлы була, чын дус янында караңгылык та кимеп китә, авырлыклар да җиңеләя», – дигән.

Ярату ул – үзең турында оныту. Чын дус дустының мәнфәгатен үз мәнфәгатьләреннән өстен куя, ул синең өчен тырыша (яхшы врач кебек). Табиб та бит: укол кадарга да мөмкин, әче дару бирергә дә, операция ясап кайсыдыр җиреңне кисеп авырттырырга да мөмкин, ләкин ул аны синең өчен эшли. Кайвакыт дусларның туры сүзен кабул итә алмыйбыз, үпкәлибез, араларны өзәбез. Хаталарыңны күреп төзәтергә тырышучыларны читкә тибәреп, яныңнан куып харап була күрмә.

Зәйнулла ишан: «Акчаң булса, дуслар табып була, әмма дусларның мәхәббәтен акчага сатып алып булмый», – дигән.

Хуҗа Насретдиннан «Дусларың күпме?» дигәч: «Әйтә алмыйм әле, бу арада тормыш яхшы бара, чын дуслар авырлык килгәч кенә беленә», – дигән.

Югары күтәрелгән кешенең кем икәнен дуслары тиз белә. (*Хакыйкатьтә, урын кешене бозмый, бозык кешегә үзенең яман гадәтләрен күрсәтергә мөмкинлек бирә. Урынга күтәрелү бөекләрне тагын да бөегрәк итә, җүнсезләрне тагын да җүнсезрәк итә).* Вазыйфаи дәрәҗәсе түбән төшкән кеше дусларының кем икәнен бик тиз белә.

Җәләлетдин Руминың, Локман Хәкимнең, дусты кулыннан ачы кавынны канәгать булып ашавы турындагы хикәясен, дусларыңның туры сүзләрен дөрес кабул итә бел, шулчак Локман Хәким кебек хикмәт иясе булырсың, тик кабул итәргә генә кирәк.

* * *

Локман Хәким улы әтисенә мөрәҗәгать итеп: «Әтием, син инде акыл иясе, әмма кешеләр синең турыда теләсә-нәрсә сөйли, сәбәбе нидә икән?» дигән. «Улым, – дигән Локман Хәким. – Кеше фикерен ишетәсең килсә, әйдә, юлга чыгабыз. Локман Хәким ишәккә утырган, малае янәшә бара икән. Кешеләр: «Нинди мәгънәсез карт, үзе утырган, малае җәүяләп бара», – диләр икән. «Ишеттеңме? Әйдә, син утыр, – дигән атасы. – Мин җәяүләп барыйм». Болар юлны дәвам итә. Очраган кешеләр: «Нинди әдәпсез малай, атасы җәяүләп бара, улы утырган», – дип гаепләгән. Шуннан болар икәүләп ишәккә утырган. Кешеләр: «Нинди мәрхәмәтсез бәндәләр, бер ишәккә икәү утырганнар», – дип ишәкне җәлләгәннәр. Болар төшеп, ишәк янәшәсеннән бара башлаган. Кешеләр: «Кара инде бу җүләрләрне, ишәкләре дә бар, җәяүләп баралар», – дип көлә икән.

Локман Хәким кызык итеп, ишәкне җилкәсенә күтәргән, ишәк куркып сикергән, ерак түгел текә яр бар икән, шуннан егылып төшеп үлгән. «Улым, – дигән Локман Хәким, – Кеше сүзенә карамыйча, үзебезчә эшләсәк, максатка ирешер идек, кеше сүзенә карап ишәксез калдык», – дигән.

Һәркем үз дәрәҗәсенә карап киңәш бирә, үзенә карап башкаларга бәя бирә. Бүген Интернет дигән нигъмәт бар. Күпләр шул нигъмәттән унитаз ясый – эчендә нәрсәсе бар, шуны Интернетка чыгара. Аннары «Фәлән кеше турында шулай әйткәннәр, болай әйткәннәр» дип бөтен кеше шаулый. Тираж өчен күп кенә газеталар да пычрак таратуда Интернет белән ярыша. Белегез, кем турында сүз барса да, автор үзенә бәя бирә, үзенең эчке дөньясын күрсәтә. Алда бу турыда әйткән идем. Эшлекле кешегә үзен күрсәтер өчен эше җитә. Аның вакланып җавап би-

реп торуга хәҗәте юк. Мөрәҗәгать итәсем килә: «Әй, Интернетка иман китерүчеләр, тәүбә кылыгыз, хәкимнәрнең Хәкиме – Аллаһ бар, ул гына гадел хөкем итүче. Аның урынына үзегезне куеп, кешеләр турында хөкем чыгарабыз дип, начарлык таратып харап була күрмәгез. Бар нәрсә дә үзеңә кайта. Кыямәт көнендә һәр сүзең өчен җавап тотасы бар. Тираж дип, Кыямәт көнендә йөзебез кызарырлык материаллар бирмик. Аллаһ Раббыбыз, безгә бүген җавап бирүнең мисалын да күрсәтте. Ул – кесә телефоны (сотовый), сөйләштеңме – түләргә кирәк. Дәшми торса, һәр кеше дә башкаларга акыллы булып күренә, аны аңлаучы гына сирәк. «Киемеңә карап каршылыйлар, акылыңа карап озаталар» дигән мәкаль бар. Ә инде акыл сүзгә карап бәяләнә.

«Бернинди нигезсез кешеләр турында яман уйлаудан сакланыгыз, чөнки начар уй – сүзләрнең иң яманы. Кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, көнләшмәгез, ачуланышмагыз, бер-берегезне ташламагыз, Аллаһның коллары булган хәлдә бер-берегезгә кардәшләр булыгыз» (Хәдис).

«Берәү берәүнең бер кимчелеген яшерсә, Аллаһ Кыямәт көнендә аның бер гөнаһын яшерер» (Хәдис).

### 5. Локман Хәкимнеке булуы ихтимал нәсыйхәтләр.

– Кешеләргә рәхмәт әйтә белү – яхшы күңеллелек сыйфаты.

– Тормыш – ул үзенә күрә бер көзгедер. Кеше анда үз киресен күрә. Әгәр ачуланып карасаң, тормыш та сиңа ачулы булыр. Аңа даими елмаеп кара, әнә шунда тормыш та сиңа дуслык кулын сузар.

– Тормышта хатын һәрвакыт дошман кебек, гел сине ничек итеп үзенә буйсындыру турында баш вата.

– Якын кешеңнең сине рәнҗетүе – ике дошманның рәнҗетүеннән дә яман.

– Күркәм сыйфат вә холык белән бизәлмәгән кешене һичнинди матур киемнәр күркәм итә алмас, гөнаһ-хаталардан сакланмаган кемсәнең калебе һич гаеп-кимчелектән азат булмас.

www.darulkutub.com

– Яхшы кеше эштән ләззәт ала.

– Байлыгың артканга сөенмә, кимегәнгә кайгырма – бәхетле булырсың.

– Кеше бәхетеннән көнләшмә, аның белән бергә сөен, ул бәхет синеке дә булыр. Көнләшсәң, зыяны үзеңә генә булыр.

– Үлемнән кала алмассың, кешечә үләргә тырыш (иман белән). Яшәү табигый булган кебек, үлем дә, авыру да табигый. Кайсы гына килсә дә, берәүне дә гаепләмә. Аны тәкъдир дип кабул ит.

*Ягъкуб галәйһиссәлам үлем фәрештәсе белән дус була. Бервакыт үлем фәрештәсе аңа кунакка килә. Ягъкуб галәйһиссәлам сорый: «Йә үлем фәрештәсе, син кунакка килдеңме, әллә җанымны алыргамы?» «Зиярәт кылырга килдем», – ди үлем фәрештәсе. Ягъкуб галәйһиссәлам әйтә: «Минем сиңа бер үтенечем бар». «Нинди?» «Син минем җанымны алырга килер алдыннан кисәтеп куй әле». «Ярар, хуш, мин сиңа алдан ике, я өч илчемне җибәрермен». Ягъкуб галәйһиссәламнең әҗәле җиткәч, аңа үлем фәрештәсе килә. Ул сорый: «Син мине зиярәт итәргә килдеңме? Әллә җанымны алыргамы?» «Җаныңны алырга». «Син бит ике, я өч илче җибәрермен, дигән идең». «Мин шулай иттем дә. Кара чәчләреңә чаллык җибәрдем. Куәтле тәнеңә зәгыйфьлек җибәрдем. Туры умырткаңа кәкрелек җибәрдем. Йә Ягъкуб, болар минем кешеләргә килүче илчеләрем инде», – ди үлем фәрештәсе.*

– Тынычлыкта ашалган гади аш берәүнең тәкәбберлек белән биргән тәм-томыннан афзаллырактыр.

– Һөнәр – шундый ат ки, аңа атланган кешене рәхәткә җиткезәчәк.

– Кайгы килми – кешенең дус икәнен белеп булмый.

– Һәркемгә үз эше бирелгән, һәр эшнең үз вакыты бар.

– Аллаһ үз колын сөйгәндә бу дөньяда аның кайгыларын күбәйтергә вә аннан нәфрәтләнгәндә мал-дөньясын киң итәргә дә мөмкин. Чөнки бу дөнья сынау дөньясы.

– Сине белүчеләр алдында мактанма, көлкегә калырсың, алар синең турында барын да белә.

www.darulkutub.com

– Яхшы сүз, тәмле тел белән, көч белән ирешә алмаганга да ирешеп була.

– Түрәләр белән сирәгрәк очрашырга тырыш, очрашырга туры килсә, матур әңгәмә кор. Тәнкыйтьләп ачуларын чыгарма, үз фикереңне тагарга тырышма, аларны үзгәртеп булмый, үзеңә, якыннарыңа зыян китерүең бар. *(Элек берәүне партиягә алалар икән, аннан сораганнар: «Партиянең эчке һәм тышкы сәясәт буенча фикерләре турында ни уйлыйсың?» – «Мин партиянең эчке һәм тышкы сәясәт буенча фикерләрен өйрәнәм, хуплыйм һәм яклыйм». – «Ә хөкүмәтнең эчке һәм тышкы сәясәт буенча фикерләрен?» – «Аны да өйрәнәм, хуплыйм һәм яклыйм». – «Синең эчке һәм тышкы сәясәт буенча үз фикерләрең дә бармы?» – «Әйе, бар. Ләкин мин аларны хупламыйм да, якламыйм да»)* Тәнкыйть авыр таш кебек, ыргытырга көчең җитсә генә күтәр, югыйсә астында калып харап булырсың.

– Үзсүзле кеше барын да үзенчә эшләргә тырыша, кеше киңәшенә колак салмый. Шуның нәтиҗәсендә үз фикеренең корбанына әйләнә. Үзеңнең фикерең булу – син хаклы дигән сүз түгел. Үз фикереңне үзгәртә алмыйсың икән, үзгәртмә, берәү дә аны таләп итми. Әмма фикерең белән башкаларга яшәргә һәм эшләргә комачаулама. *(Ә нәрсә соң ул фикер алышу? Син үз фикерең белән хуҗа янына керәсең һәм аның фикере белән чыгып китәсең.)*

– Муллыкны теләсәң, бәхетле булганыңда да дусларыңны арттырырга омтыл. Диңгез һәр чакта тулы булса да, барыбер елга суына мохтаҗдыр.

– Балаларыгызга яхшылыкларны сеңдереп үстерегез, аларга бәхетне фәкать шул фазыйләт кенә бирә.

– Әүвәл дини гыйлем эстә, аннары кәсеп-һөнәргә өйрәнеп, хәләлдән мал-мөлкәт туплап, соңыннан өйлән! Чөнки, әгәр гыйлем алган вакытта мал-дәүләт табуга керешсәң, шөбһәсез, гыйлем алуда гаҗиз каласың. Мал-мөлкәтең күбәеп дөнья куута теләгең артачак, шунда байлык белән мәшгуль булып гыйлемнән мәхрүм каласың. Гомерең вә кыйммәтле вакытың бушка китәчәк. Соңыннан балаларың күбәеп китә, гаилә мәшәкатьләре артып, алар янында калачаксың. Әгәһ бул! Ун ел кәсеп-һөнәрсез, ри-

зыксыз калсаң да, гыйлемнән баш тартма! Чөнки гыйлемнән баш тарту – бөтен яхшылыклардан баш тарту ул. Гыйлемнән тамак, дәрәҗә яки башка дөньяви хаҗәтләр сәбәпле китү – бик зур хата. Бәлки тормышның янә дә кыенрак, бәла вә афәтләр белән мәшәкатьле упкынга тартылуга сәбәп булачак. Зинһар, гыйлем тәһсиленнән ваз кичмә. Гыйлем вә фазыл әһелләренә үтә дә ихтирамлы вә игътибарлы бул! Яше зур булганнарга остаз итеп кара, ә яшьрәкләрне исә ышанычлы шәкертләрең кебек кабул ит. Әгәр ярдәмнәреннән файдаланган булсаң, үз атаң вә балаң урынына күреп, аларны даимән ачык йөз белән каршы ал. Бу гүзәл холкың аларның гыйлемгә булган теләкләрен көчәйтергә мөмкин.

– Һәрбер мөшкел эш акыл ияләре сәбәпле ислах кылыныр.

– Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләгә иң якын булучы кешеләр – дөньяда иң күп ачлык һәм сусау татучылар. Адәм балаларына иң куркыныч нәрсә – корсак теләкләрен канәгатьләндерү. Шуның аркасында Адәм белән Хава анабыз җәннәттән мәшәкать дөньясына куылды. Раббылары аларга ул агачтан ашарга тыйды. Әмма алар нәфесләренә буйсынып аннан ашады һәм аларның гаурәтләре ачылды. Тәхкыйк, ашказаны – һәртөрле теләк-шәһвәт чыганагы.

– Маймыл шыксызрак булган саен, яклырак, кыланчыграк була.

– Үз кардәшеңнең сүзен дәшмичә тыңлап бетер, гәрчә аны ишетүгә теләгең булмаса да, аның хөрмәтен урынына җиткер. Әгәр телеңә артык сөйләшергә юл куйсаң, димәк, идарә итү тезгенен шайтанга тапшырган буласың. Тел белән кылынган җәрәхәт – кылыч белән кылынган җәрәхәттән авыррактыр.

– Бер утыннан учак тергезеп булмаган кебек, дуслардан башка максатка ирешеп булмый.

– Җитәкчеләре үз мәнфәгатен халык мәнфәгатеннән өстен куйган җәмгыять алга бара алмый, харап була.

– Бар кешегә дә ярарга тырышкан кеше берәүгә дә ярамый.

– Хатының белән күркәм мөгамәлә кыл, аны иркәлә. Назны читтән эзләргә мәҗбүр булмасын.

www.darul-kutub.com

– Кешене һәлак итүче сыйфат – ачкүзлелек. Ул кешене, барына канәгать булмыйча, ышанычсыз әйбер артыннан чабарга мәҗбүр итә, нәтиҗәдә, кеше булганын да югалта. Черки дә тулы канлы тормыш өчен тырышлыгы белән башкаларны бимазалый *(Яшь көя белән карт көя тун кимереп ята икән. Карт көя нәсыйхәт кылып: «Балам, барына канәгать бул, шушы тунны кимереп кенә ят, бер үк кешеләр янына чыгып йөри күрмә», – ди. Баласы: «Әнием, ялгышасың. Кичә мин кешеләр янында очып йөрдем, алар мине алкышлап кул чапты», – дигән. Ягъни, үзен үтерергә тырышканнарын аңламаган)*.

– Кешенең кыяфәтенә түгел, акылына карарга өйрән. Һәр матур киенгән, матур күренгән кеше акыллы түгел. Хәтта бүләк бирелү дә, вакыты белән, ул кешенең яхшы икәнлеген күрсәтми. *(Урман җәнлекләренә бүләк өләшкәннәр. Ул арысланга – батыр булганы өчен, бүрегә – кыю булганы өчен, төлкегә – хәйләкәр булганы өчен, куянга – җитез булганы өчен бирелгән. Урман һавасын бозмасын дип, сасы көзәнгә дә өлеш чыгарганнар.)*

– Акыллы булу бай булудан өстен, байлык бетәргә мөмкин, акыл кала.

– Эчкерсез, кешелекле бул, чөнки кемнең ул сыйфатлары зәгыйфьләшсә, шөбһәсез, аның кешеләр арасында абруйхөрмәте дә төшәчәк.

– Ихтыяждан артык нәрсәләргә бирелүдән үзеңне тый!

– Мал-дәүләткә һәм дәрәҗәгә күңелеңне бирмә, чөнки Аллаһы Тәгалә алар турында синнән сорау алачак.

– Язмыш үзгәрә дисәләр – ул начар якка үзгәрә, чөнки яшьлектән соң картлык килә. Чибәрлегең, сәламәтлегең кими икән, яхшы гадәт-сыйфатларың артсын, шулчак яшәү гомерең уңышлы сәүдә кебек була.

– Яшьләрне тәнкыйтьләгәнче үзеңнең яшь вакытыңны исеңә төшер, яшьлек Адәм галәйһиссәламгә дә тыелган җимеш ашарга мәҗбүр итте. Картлардан зарланганчы, үзеңә бу көн киләсен уйла. Иң тиз үтә торган «кимчелек» – яшьлек.

– Ышанган кешең дә һәлак итәргә мөмкин, шикләнгән кешең дә коткарырга мөмкин.

www.darul-kutub.com

– Бер хәкимнән сорадылар: «Сездәге белемнең уннан берен дә белмәүчеләр сездән берничә тапкырга күбрәк танылды. Моның сәбәбе нәрсәдә?» – «Мин белү өчен өйрәндем, алар танылу өчен!»

– Локман хәкимнән: «Авыруга нәрсә ашатыйк?» – дип сорадылар. «Ачы сүздән башка бөтен нәрсәне ашата аласыз».

– Кылыч ясаучы – үтерүче түгел, аны кулланучы яманрак, яла ягучыдан шул яланы кулланучы начаррак.

– Качыр көзгедә ялын күргәч, үзен ат дип горурланмакчы булган, әмма ишәктән туганы исенә төшкән.

– Атлар юк җирдә ишәкне ат дип зурлыйлар. Ул аңа карап атка әйләнми. Иярен алыштырганга карап кына ишәк ишәк булудан туктамый. *(Милицияне полициягә, Авыл Советларын муниципаль берәмлеккә алыштырудан әллә нәрсә үзгәрми.)*

– Бүре көтүчеләрнең сарык ите ашап утырганнарын күреп шаккаткан, «Әгәр бу эшне мин эшләсәм – бөтен дөньяга тавыш кубар иде», – дигән. Дөнья шулай корылган: берәүнең бәхете икенчене бәхетсез итә. Мәче бәхетле булса – тычкан һәлак була, тычкан бәхетле булса – мәче ач кала. Берәү җиңү шатлыгын татысын өчен бик күпләр җиңелү ачычын татырга тиеш. Кемдер күтәрелсен өчен кемдер урыныннан төшәргә тиеш.

– Акыллы кеше үз кимчелекләренә ачынып утырмый, бәлки үзенә дөрес нәтиҗә ясый. Начарлык эшләдең исә, шунда ук яхшылык кыл, чөнки синең кылган яхшылыгың ул начарлыкның юлын каплый. Әгәр үзеңне борчый торган нәрсәләргә сабырлык саклый алдың икән, бәс, үзеңне җиңү белән котла. Аллаһка тәвәккәл ит, ышан, шул сиңа бик җиткән. Яхшы эш – бәрәкәтле гомер, димәктер. Хәерле эшкә омтылсаң, әлбәттә, ирешерсең. Ахирәт савабы дөнья ләззәтеннән өстенрәктер.

– Башкаларга акыл өйрәткәнче, иң элек үз балаларыңа акыл өйрәт.

– Ышану көче физик көчтән куәтлерәк.

– Кешенең иң куәтле коралы – зирәк акыл.

– Бу дөньяда һәрбер нәрсә үзгәрә, әмма фазыйләт бер дә үзгәрми.

– Олуг акыл ияләре үз алдына максат куя, калган адәмнәр исә үз теләкләре артыннан иярә.

– Иң яхшы байлык – күңел байлыгы.

– Иң начар үкенү – ахирәттәге үкенүдер.

– Иң начар адашу – тугры юлны тапканнан соңгы адашудыр.

– Кешене кеше итүче, аны Аллаһка якын итүче вә ахирәттә күтәрүче бердәнбер фазыйләт – канәгатьлектер.

– Иң биек бина да җирдән күтәрелә.

– Вөҗданнан башка бөтен нәрсәне су белән юу мөмкин.

– Һәр эшне башлау алдыннан әүвәл Аллаһ ризалыгын уйла, алай булмаса, кылган эшләренең бөтенесе юкка чыгып заяга китә.

– Бөек эшләрне кылырга ният итү – каһарманнарга хас сыйфаттыр, сабырлы булу исә хакыйкый ирләргә хас фазыйләттер.

– Җиһанны гизеп үзләрен җәбер кылучылар һәм киресенчә бер җирдә яшәп акылы вә гыйлеме белән җиһанны гизүче кешеләр дә бу дөньяда күп.

– Мөгамәлә киемен пычрак тотучы адәм әүлияларга якынлаша алмый.

– Берәр кешене алдамау адәмнең сакчыллыгына мисал булса, берәүгә алданмау – акылның камиллегенә дәлил булып тора.

– Ошамаган күп нәрсәләреңә сабыр итмичә, ошаган нәрсәләреңнең азына да ирешә алмыйсың.

– Һәрнәрсәнең зәкяте бар. Акылның зәкяте ахирәтне уйлауда.

– Йөзеңнең нурлы пәрдәсен теләнчелек белән югалтма. Начарлыкка юлдаш булганнар аның бәласеннән иминлек таба алмый.

— Начар вә фәхеш җирләргә йөргән адәм яла-гайбәткә дучар була.

— Йөрәгең үзеңә нәсыйхәтле булса, Аллаһ аны үз химаясендә саклый.

– Аллаһы Тәгалә кешеләргә гадел мөгамәләдә булучының кадерен күтәрә.

www.darul-kutub.com

– Аллаһы Тәгалә әйтә: «Минем тәкъдиремнән риза булмаучы сынауларыма сабыр итмәс, нигъмәтләремә шөкер кылмас, биргәнемә риза булмас, шулай булгач, үзенә Миннән башка раббы эзләсен».

– Бер кеше Әбу Йәзид әл-Бистамига әйтә: «Йә остаз, мин гыйбадәтемдә шатлык таба алмыйм». Остаз әйтә: «Чөнки син Аллаһы Тәгалә урынына гыйбадәткә табынасың. Гыйбадәттән шатлык һәм ләззәт табарга теләсәң, Аллаһка гыйбадәт кыл».

– Бөтен гамәлләреңдә ихлас ниятле бул, һәрвакытта да фәкать хәләл нәрсәләрне генә куллануда тырышлык куй.

– Саранлыктан саклан! Чөнки ул газапны күбәйтә, дошманлык вә нәфрәткә сәбәп була.

– Күп көлүдән саклан! Чөнки күп көлү – калебне үтерә, йөзеңнең нурын югалта. Калебе терек булган исә бетмәс зиһенгә, әдәп-әхлакка вә башка фазыйләтләрдә үрнәк булуга иядер.

– Мал-мөлкәтне заяга исраф кылу – көфрани гамәл. Уйламыйча байлыкны сарыф итү бөлүгә китерә.

– Баштан кылып куелган хәер-изгелекләрегезгә соңыннан да изгелек өстәп торыгыз, ягъни даими хәерле гамәлләр кылыгыз, мәсәлән, ничек кошның канатындагы кечкенә каурыйлар зур каурыйларны ныгытып тора, сез дә шулай тырышыгыз.

– Чиста күңелле кеше үзен гел тынычлыкта хис итә, ә берәүгә хыянәт һәм начарлык кылырга җыенган кеше исә борчу-тынычсызлык һәлакәтенә дучар була.

– Кояш нурын томалап булмаган кебек, хакыйкатьнең дә чырагын сүндереп булмый.

– Күп артык сүз ишетеп торучыны рәнҗетәдер.

– Игенчелек белән шөгыльләнү бик тә хәерле, бәрәкәтле эштер, үз халкыңа бик күп хәер-бәрәкәт эсти.

– Кем ки дошманлыкны чәчсә, әлбәттә, мәшәкать-кыенлыкны урыр.

– Тәкәбберлек һичкемнең кадер-кыйммәтен арттырмас, ул давыл эчендәге бер җил генә булып тора.

– Тау башындагы зур ташларны күчерү сорап алынган рәхмәт сүзләрен ишетүгә караганда җиңелрәктер.

www.darul-kutub.com

– Берәүнең юмартлыгы, шәрәфәте нихәтле күп булса, шуның кадәр башкалар да аның кайгысын уртаклаша.

– Тазалык өч төрледер: дин тазалыгы, мал тазалыгы һәм тән тазалыгы. Дин тазалыгы – нәфесне авызлыклау вә күңелне хәсәдтән пакьләү. Мал тазалыгы хакларны хаклауда. Тән тазалыгы исә – аз ашауда һәм аз йоклаудадыр.

– Ир-егетләргә игътибар күзе белән кара, түбәнсетү күзе белән түгел. Хатын-кызларга шәфкать күзе белән кара, шәһвәт карашы белән түгел.

– Һәркем, дөнья тәнбиһләренә карамастан, тугры юлга кермәсә ахирәт газабына дучар ителер.

– Әгәр берәүгә нәсыйхәт кылуны теләсәң, әүвәлдә үзеңә нәсыйхәт кыл. Үзеңне нәсыйхәтли алсаң, башкаларга да нәсыйхәт кыл.

– Яманнардан кач һәм яхшыларга кушыл, әгәр ялгыз булсаң – шайтан белән булырсың. Әгәр яманнар белән булсаң, яманга әйләнерсең.

– Үзеңнән түбәнрәк кешеләргә золым итү – акылның түбәнлегеннәндер.

– Җәза бирергә кадир була торып та кичереп җибәрү – киң күңеллелектән.

– Нигъмәтнең бетүенә золым сәбәп була.

– Утны утын яндырып торган кебек, акылыңны да әдәп белән кыздырып тор.

– Әдәпсез акыл коралсыз сугышчы мисалындадыр.

– Әдәп – бөтен фазыйләтләргә җиткерүче вә төрле максатларга ирештерүче ысулдыр.

– Нигъмәт – ул шундый гүзәл нәрсәдер, аның мәгънәсе исә – шөкердер.

– Шөкер белән нигъмәткә кимү килмәс.

– Лаексыз кешеләрдән үз вакытында котылуга хәрәкәт кыл.

– Кешеләрнең начары гозерне кабул итми, башкаларның гаепләрен яшерми вә хаталарын кичерми.

* * *

Аллаһ Раббыбыз безгә пәйгамбәрләр җибәрде, китаплар иңдерде, хикмәт ияләрен җибәрде, һәммәбезгә шуларның нәсыйхәтләрен, сүзләрен хикмәт белән тормышта куллануыбыз зарур. Аллаһны танымаган кешеләргә нәсыйхәт бирү – тамырсыз агачка су сибү кебек. Күпме генә сипсәң дә, ул агач үсмәячәк. Балаларыбыз әхлаклы булсын өчен, иң әүвәл Аллаһны таныту зарур. Мәшһүр татар дин әһеле Ризаэддин бине Фәхреддин: «Динсез тәрбия – тәрбиясезлек», – дигән. Бөек Раббыбыз әйтә: «Кәлимәтәң таййибәтәң кәшәҗәратил таййибәтин әсълүһәә сәәбитүү үә фәргүһәә фиссәмәәәәә, түэтиии үкүләһәә күллә хииним би изни раббиһәә», ягъни: «Яхшы сүз (иман) – тамыры җирдә, ботаклары югарыда булган нигъмәт агачына ошаган. Ул агач Раббыңның рәхмәте илә һәрвакыт җимеш бирә» («Ибраһим» сүрәсе, 24-25 нче аять).

Аллаһы Тәгалә калган гомерләребезне хәерле гомерләрдән кылып, телләребезгә, күңелләребезгә сабырлыклар биреп, Үзе риза булырлык итеп үтүләребезне насыйп итеп, актык урыннарыбызны җәннәттә кылса иде. Әмин.

* * *

*Бер кеше Хәсән Басри хәзрәтләренең янына килеп: «Фәлән синең турында начар сүзләр әйтте», – диде. – «Кайчан?» – «Бүген». – «Кайда?» – «Өендә». – «Аның өендә нишләдең?» – «Кунакка бардым». – «Кунакта нәрсә ашадың?»*

*Ул кеше сигез төрле ризык исемен санады.*

*Шунда Хәсән Басри:*

*– Ул адәмнең сигез төрле ризыгын эчеңә сыйдыргансың, ә бер сүз сыймадымы? Кит моннан, – диде һәм гайбәтчене куып чыгарды.*

***«Үгет-нәсыйхәтләр һәм гыйбрәт-хикмәтләр» китабыннан.***

www.darulkutub.com

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим**

# Нигезне саклау – илне саклау

**Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-ражииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гәәләмииин. Үәссаләәтү үәссәләәмү гәләә расүүлинә Мүхәммәдиү үә гәләә әәлиһи үә әсъхәәбиһи әҗмәгииин.**

**Газиз дин кардәшләрем, әссәләәмүгәләйкүм үә рахмәтүллааһи үә бәракәәтүһ!**

Әлхәмдүлилләәһ, бүген күп төзибез. Халкыбыз тырыш. Төрле җайсызлык, авырлыкларга карамастан, авылларда, шәһәрләрдә яңадан-яңа йортлар калка. Зәйнулла ишан: «Акчаң булса – үзең теләгәнчә йорт салып була, әмма йорт эченә тынычлык сатып алып булмый», – дигән. Әйе, өй ул – тыныч, матур итеп яшәүне тәэмин итә торган урын, кечкенә генә күркәм бер дәүләт булырга тиеш. Ир кеше өй салырга, агач утыртырга, балалар тәрбияләп үстерергә тиеш. Өйләнү «өйле булу» дигән сүздән алынган. Өйләнәсең икән – өй салырлык, өйне алып барырлык сәләтең дә, гадәтең дә булу кирәк. Өй салуның максаты – үзеңнең җәмгыятьтәге урыныңны, байлыгыңны күрсәтү өчен түгел, тәртипле, тәрбияле балалар үстерү өчен булса хәерле. Болын кадәр өйдә ике кеше яшәп ята икән – ул

www.darul-kutub.com

инде нинди генә затлы, зиннәтле йорт булмасын – зур кабер кебек. Өебез зур кабергә әйләнмәсен дисәк, төзи башлаганда ук Аллаһка тәвәккәл кылып, «бисмилләһ» дигән изге дога белән башларга, хәләл акча белән төзергә кирәк. Хәрәм белән төзелгән йортта тынычлык та, бәрәкәт тә юк, аның киләчәге дә булмый. Төзеп бетергәч, Аллаһка шөкер кылып, дога белән, хәләл ризыклар белән, Аллаһ кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәү кирәк. Әгәр тәртипсез, бозык тормыш барса, ул нигездән фәрештәләр кача, тынычлык китә, ахырдан ул нигез бетә. Халыкта да бит «догалы нигез», «тынгысыз нигез» дигән сүзләр бар.

Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәлам, Кәгъбәтуллаһны төзеп бетергәч, дога кылган: **«Раббәнәә тәкаббәл миннәә. Иннәкә әңтәссәмиигүл гәлииим. Раббәнәә үәҗегәлнәә мүслимәйниләк. Үә миң зурриййәтинәәә үммәтәм мүслимәтәлләк. Үә әринәә мәнәәсикәнәә үә түбе гәләйнәә. Иннәкә әңтәттәү үәәбүр-рахииим. Раббәнәә үәбегәсфииһим расүүләм минһүм йәтлүү гәләйһим әәйәәтикә үә йүгәллимүһүмүл китәәбә үәл хикмәтә үә йүзәккииһим. Иннәкә әңтәлгәзиизүл хәкииим».** Ягъни *(мәгънәсе): «Ий Раббыбыз! Эшебезне кабул ит! Син Ишетүче һәм күңелләрне Белүче. Ий Раббыбыз! Икебезне дә Үзеңә итагать итүче мөселманнардан кыл, нәселебездә дә мөселман булган җәмәгатьне насыйп ит, безгә хаҗ гамәлләрен өйрәт, тәүбәләребезне кабул итеп, гөнаһларыбызны гафу ит! Син, әлбәттә, тәүбәләребезне кабул итүче, рәхимлесең. Ий Раббыбыз, Сиңа буйсынучыны безнең өммәтебездән җибәрсәң иде. Ул илче өммәтенә Синең аятьләреңне укыр, аларга Китапны-хикмәтне өйрәтер, өммәтен кяферлектән пакьләр, дөреслектә, Син җиңүче һәм хикмәт иясе».* (Бу хакта «Бәкара (Сыер)» сүрәсенең 127-129 нче аятьләреннән карый аласыз.)

Димәк, нәрсә генә төзесәк тә, ул безгә мөселман булып яшәргә, үзебездән соң мөселман булган балалар тәрбияләп калдырырга ярдәм итәргә тиеш. Шулай булмаса, ул бозыклык таратучы, халыкны бетерүче, юлдан яздыручы булачак.

www.darul-kutub.com

Хәзерге вакытта «тел бетә, дин бетә» дип зарланабыз, кемнәрне генә сүкмибез, пикетлар ясыйбыз. Бер-беребездән ярыша-ярыша салган өйләребездә, зур чыгымнар тотып, туйлар ясап корган гаиләләребездә – ягъни үз өебездә, үз гаиләбездә татар телен дәүләт теле итәргә, ислам динен дәүләт дине итәргә нәрсә комачаулый, кем комачаулый? Конституциядә дин иреге рөхсәт ителгән. Мәчетләр бар. Дини белем алырга, балаларны укытырга бөтен мөмкинлекләр тудырылган, әле 30 ел элек кенә бу турыда хыяллана да алмый идек. Шөкер итеп хәрәкәтләнәсе урынга, без зарланабыз, кемнедер гаеплибез. Татар телен кайгыртучыларның балалары татар телен белми, динне кайгыртучылар, ничек итеп дин тотарга өйрәтүчеләр – динсез (динсезләргә ошый, ярый торган итеп ничек динне алып барып булсын ди), авылны кайгыртучыларның балалары шәһәрдә, илне кайгыртучыларның балалары чит илдә. Алай итеп телне дә, динне дә, илне дә, милләтне дә саклап булмый. Мәгарифтә берсеннән-берсе уңышлы «реформа» ясаучыларның балалары, нишләптер, үзләре реформалаган мәктәп-институтларда түгел, чит илләрдә белем ала.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.): «Һәркайсыгыз көтүче һәм һәркем үз көтүе өчен җавап бирә (кемнәр өчен җавап бирергә тиешсез, шулар өчен җаваплы)», – дигән. Көтүче көтүен таралып китүдән һәм явыз җәнлекләрдән саклый. Гаиләбез, илебез тарала икән, төрле бозыклыклар үтеп керә икән – без нинди көтүче?! Кыямәт көнендә нәрсә дип җавап бирербез? Без бүген көтүебезне түгел, күбрәк нәфесебезне кайгыртып яшибез! Алай итеп гаиләне дә, җәмгыятьне дә саклап булмый.

Бер шайтан эшсез көенчә аягын селкетеп утыра икән. Берәү аннан: «Син нишләп эшсез утырасың?» – дип сораган. Шайтан: «Нәфесләрен генә кайгыртып йөргән бәндәләр безнең бөтен эшне алып бетерде, без эшсез калдык», – дигән. «Сезнең нәфесегез 70 шайтаннан яманрак» дигән хәдис тә бар.

Аллаһ Раббыбыз Коръәни-Кәримдә («Тәхрим (Хәрәм)» сүрәсе, 8 нче аять): **«Йәәәә әййүһәлләзиинә әәмәнүү**

www.darul-kutub.com

**кууу әңфүсикүм үә әһлиикүм нәәраү үә куу зүһәннәәсү үәл хиҗәәраһ»**, – ягъни: «Әй мөэминнәр, үзегезне һәм өй җәмәгатегезне җәһәннәм утыннан саклагыз (үзегез шәригать хөкемнәрен дөрес үтәп, гаиләгезгә шәригать хөкемнәрен дөрес өйрәтегез), ул җәһәннәмнең утыны – кешеләр һәм ташлар», – ди. Димәк, ир кешенең эше матур, зиннәтле өй салу белән генә бетми, ул шул өй әһелен (гаиләсен) җәһәннәм утыннан саклаучы булырга тиеш.

**Моның өчен, беренче чиратта, әлбәттә, динне саклау кирәк.** Динне өйрәтү һәм алып бару өчен мәчет-мәдрәсәләр кирәк. Үзләре кечкенә йортларда яшәсәләр дә, бабаларыбыз зур-зур мәчет-мәдрәсәләр төзегән һәм тоткан. Бүген кайбер җирләрдә, зур-зур зиннәтле өйләр арасында, мескен генә мәчет утыра яисә зур итеп, матур итеп төзелгән мәчетнең ягарына юк, я имам тотарлык хәле юк. Картаеп кына иманга килгән бер карт кулына мәчет тапшырылган. Авылда мәчет кебек йөздән артык йорт бар, һәркайсының ягарына утыны (яисә газ өчен түләргә акчасы) бар, ә йөз йорт бергәләшеп бер мәчетне тота алмый. Моның өчен күп кирәкме? Юк бит. Шул йөз йорт бер генә шешә аракыны кимрәк эчсә дә, 20 мең сум акча була. Мәчет тотуга караганда, рюмка тотуны артык күргән халык динне саклый алмый. Дин бетсә – халык бетә. Аллаһ Раббыбыз динсез халыкны җир йөзендә тотмый, икенче халык белән алыштыра. Безнең көннәрдә туучыга караганда үлүче күбрәк икән – Аллаһ урынына шешәгә табыну безне шул хәлгә китереп җиткергән. Әле соң түгел, тәүбәгә килик.

Милләтебезнең хәле мактанырлык түгел. «Фәлән җирдә дистәләгән татар яши», – дип горурланырга яратабыз. Мөгаен, «Фәлән җирдә фәлән татар әбие, татар бабае яши» диярге кирәктер. Рус язучысы Михаил Шолоховның «Күтәренгән чирәм» романында Щукарь карт «Яшәсен әбиләр» ди; «Нигә болай дип әйтәсең» дигәч: «Алар бәби тапмый», – дип җавап бирә. Бүген телевидениедә татарлар турында хәйран матур тапшырулар бара, төрле төбәкләрдә яшәүче татарларны

www.darul-kutub.com

күрсәтәләр. Кызганыч, күп очракта җырчы, биюче әбиләрне, гармунчы бабайларны, мәчеттә утыручы 3-4 картны күрсәтүгә кайтып кала. Алар нинди генә матур экзотика булмасын, аларны нинди генә конфет кәгазенә төреп күрсәтмик, алар инде бәби таба алмый. Ә менә алар урнына кем кала? Оныклары нинди телдә сөйләшә, нинди телдә уйлый, кемгә хезмәт итә? Менә фаҗига кайда! Без үлеп беткәч безнең урынга нинди буын килер? Татарча яшәүне нигез итеп алган яшь гаиләләрне күбрәк күрсәтәсе иде. Бәлки, «Үрнәк яшь гаилә» дип, конкурслар да уздырырга кирәктер.

Динне саклар өчен гыйлем кирәк. Пычрак савытка әллә нинди, чит илдән килгән кыйммәтле, затлы ризыклар, тәмләткечләр салсаң да, ләззәтле, тәмле ризык әзерләп булмый. Бүгенге вакытта әдәпсез, әзерлексез кешеләрнең хакыйкый остаздан башка Коръән тәфсирләрен, хәдис китапларын укып, алардан ашыгып нәтиҗә ясаулары – агу салынган казанда аш әзерләү кебек, аның үзләренә генә түгел, башкаларга да зыяны булачак. Иң әүвәл тәүбә-истигъфар кылырга, фарызлардан тыш, нәфелләрне дә үтәп, калебне чистартып, аны тәртипкә китерергә кирәк. Шәкертенең күңеле тәртиптә икәнен белә икән, хакыйкый остаз аңа гыйлем бирергә тиеш. Күп су сипсәң, гөл дә корый, күп ашасаң, ризыкның да файдага караганда зыяны күбрәк. Үзләштерелгән гыйлем үзеңә, гаиләңә, җәмгыятькә файда китерерлек булырга тиеш.

Үз заманында Гомәр радияллаһу ганһу Мәдинә халкыннан кала башка халыкларга хәдис сөйләүне тыйган. Башка халыклар аңларга һәм дөрес нәтиҗә ясарга сәләтле түгел дип санаган. Бүген күпләрнең Коръән яисә хәдис укуы үзенең нәфесен канәгатьләндерерлек дәлил эзләүгә кайтып кала.

Пәйгамбәребезнең (с. г. в.) «Бишектән алып ләхеткә кадәр гыйлем алу – фарыз» диюе – синең ничә яшьтә булуыңа карамастан, намаз, тәһарәт, госел тәртипләрен, иман шартын, кырык фарызны белергә тиеш дигән сүз. Белмисең икән – зур гөнаһ, үлгәнче өйрәнеп калырга ашык. Намаз укый белмәүченең

белмәвенә риза булып йөрүе – исерекнең аракы эчеп, кемнеңдер уен автоматы янында басып торуы кебек үк зур гөнаһ. Намаз укырга өйрәндең икән – биш вакыт намазыңны вакытында үтәргә тырыш, тәһәҗҗеткә тор, намазыңны мәчеттә җәмәгать белән укы, балаларың, якыннарың, дусларың да укысын – вәгазьлә, өйрәт. Хәләл кәсеп белән тормышыңны алып бар, гаиләңне тәрбиялә, матур яшә. «Мөселманнар ничек матур яши» дип соклanырлык булсын! Вакытың булган саен гыйлем ал. Халкыбызның бөек галиме Шиһабетдин Мәрҗани: «Өч әйбер диндә юк, әмма алар динне саклый. Алар – милли тел, милли кием, милли гореф», – дигән. Без милли азчылыкны тәшкил иткән дәүләттә яшибез. Бездә телне саклау да, гореф-гадәтне саклау да, үзебезнең киемнәребезне кию дә – динне саклау булып тора. Шулай булмаганда, без милләтебезне югалтабыз һәм икенче бер милләткә әверeләбез, ә безнең илдә икенче милләтнең, күпчелек милләтнең дине – башка. Бу очракта милләтебезне сайламыйча торып, динне саклап булмый.

«Кайсы кавемгә ошасаң – шул кавем белән кубарылырсың» дигән хәдистән куркып, безнең бабаларыбыз сакалны да үзләренчә йөрткән, әбиләребез яулыкны җәеп, я дүрт почмаклап бәйләгән, түенне дә үзләренчә төйнәгән, тастымалны да үзләренчә таслап төргән (дүрткә бөкләсәң тәре сурәте килеп чыга), төймәне дә үзләренчә – параллель итеп (аркылы итеп түгел) таккан. Руслар «закуска»га кулланган ризыкны ашарга курыкканнар.

**Икенче – нәселне саклау.** Без үзебезнең нәсел шәҗәрәсен, аның казанышларын, күренекле шәхесләрен белергә, балаларыбызны да үз нәселе белән горурланырга өйрәтергә тиешбез. Нәселең белән горурланыр өчен тарихыңны өйрәнергә, милләтеңнең үткәнен белергә, үзеңнең милли каһарманнарыңны белергә кирәк. Әлхәмдүлилләһ, соңгы вакытта Фатыйх Сибагатуллинның, Камил Әбләзовның, Вахит Имамовның, Фәүзия Бәйрәмованың, Мөсәгыйть Хәбибуллинның һәм башкаларның үткәнебез өчен горурлык уята торган тарихый

www.darul-kutub.com

китаплары дөнья күрде. Рәхмәт яусын аларга. Ләкин тарих ул – үткәнең белән горурланып, мактанып утырыр өчен генә кирәк түгел. Ул – үткәндәге хаталарны өйрәнеп, алга таба шушы хаталарны кабатламас өчен кирәк.

Мисал өчен, Русия Дәүләт Думасы депутаты Фатыйх Сибагатуллинның «От Аттилы до Президента» дигән китабын (ул 2012 нче елда дөня күрде) укыгач, горурлык хисе уяна: «Әлхәмдүлилләәәһ, мин татар», – диясе килә. Әмма «Великие татары – строители и защитники Государства Российского» дигән китабын укыгач, башка әллә нинди моңсу уйлар килә.

Дәүләтебезне югалтып, милли һәм дини азчылыкны тәшкил итеп, инде берничә гасыр яшибез, бер гасырга якын динсез дә яшәп карадык, кызларыбызны уңга-сулга сибеп килдек. Хәзер кызларыбызны төрле милләтләргә таратырлык хәлебез калмады, әмма ул әле дә булса дәвам итә. Бу урында бер мәзәк искә төшә. *(Татар, әрмән, грузин самолётта оча икән. Грузия өстеннән очканда, грузин: «Безнең кызлар алма ярата», – дип, алма сибә, ди. Әрмәнстан өстеннән очканда, әрмән: «Безнең кызлар чәчәк ярата», – дип, чәчәк сибә икән. Татарстан өстеннән очканда, татар моңаеп тик утыра, ди. «Син нишләп бернәрсә дә ташламыйсың?» – дигәч: «Безнең кызлар икегезне дә ярата, тәрәзәдән кайсыгызны ташлыйм?!» – дип җавап биргән ди, имеш.)*

Әлбәттә, кайсы гына халыкны – бигрәк тә русны, казахны, үзбәкне актарсаң, анда татар генын, татар токымын табып була торгандыр. Әмма инде алар безнең кебек түгел, безнең татар милләтенә хезмәт итүче, милләтебезне кайгыртучы да, милләтнең санын арттыручы да түгел. «Аларның канында татар каны бар!» – дип, сөенеп утыру – кәгазь акча яндырып кулны җылыту кебек. Милли хәзинәбезне саклап йөртүче, милләт аналары буласы кызларыбызның юкка чыгуы – ягъни башка кавемне тәрбияләве – бүгенге чорыбызның иң зур фаҗигасе. Дөрес нәтиҗә ясыйк, алга таба бу фаҗигале юлдан баруыбызны туктатыйк. Туган телебездә фикерлик, татарча сөйләшик,

www.darul-kutub.com

үзебезчә сөйләшә торган балалар үстереп калдырыйк. Шулай булганда гына милләтебезнең киләчәге өметле булыр. Бер хатын әйткән бит: «Кеше көен көйли-көйли, үз иремә охшаган бала таба алмадым». Дуслык та кирәк, толерантлык та кирәк, әмма ул үз милләтеңне, үз мәнфәгатьләреңне юкка чыгару хисабына булырга тиеш түгел. Бар кешегә дә ярарга тырышкан кеше берәүгә дә ярый алмый.

Кайсы гына милләт вәкиленнән: «Нәселеңдә иң беренче кеше кем булган?» – дип сорасак, ул Адәм галәйһиссәламне атар. Гарәпчә язылыштагы «адәм» сүзенең беренче хәрефе – намазда басып торучы, икенче хәрефе – рөкугъта торучы, өченче хәрефе сәҗдә кылучы булып күренә. Бу хәрәкәтләр – намазда, димәк, без – намаз укучылар нәселеннән.

Бер кеше базарда сарык сата икән. Бер-бер артлы дүрт бәндә килеп: «Казың күпме тора?» – дип сораган. «Каз түгел бу, сарык», – дигән сатучы. Бишенчесе дә килеп шул сорауны биргәч, «Мөгаен, каздыр бу» дип, аны каз бәясеннән сатып җибәргән.

Мәктәпләребездә 80-90 ел дәвамында: «Сез хайван (маймыл) нәселеннән», – дип аңлаткач, без акрынлап хайванга әйләнеп барабыз, бугай. Хайваннарда әти-әни, туганнар, ятимнәр, мохтаҗлар дигән хис юк, ул хәзер инде бездә дә бетеп бара. Нәселне кайгырту, саклау дигән сүз – матди яктан тәэмин итү генә түгел ул. Намаз укучылар нәселеннән булгач, үзебездән соң намаз укучылар калдыру да. Уңны сулдан аера башлагач, баланы намазга өйрәтә башлау лазем (тиешле). Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.): «10 яшьтә намаз өйрәнмәсә, тәрбия камчысы өстен булсын», – дигән. Аллаһ Раббыбыз Коръәни-Кәримдә: **«Иннәссаләәтә тәнһәә гәнил фәхшәәәә и үәл мүңкәр»**, – ягъни: «Вакытында укыган намаз, укучысын бозык, фәхеш эштән саклый», – ди. («Ганкәбут (Үрмәкүч)» сүрәсе, 45 нче аять). Димәк, намаз ярдәмендә генә нәселне бозыклыктан саклап була. Яхшы әйбергә яхшы әйбер кушылса гына уңай нәтиҗә чыга. Бер казан ашка аз гына бозылган,

www.darul-kutub.com

исләнгән әйбер салсаң, ул бөтен ашның тәмен ала. Шуңа күрә балаларыбыз тормыш корганда яхшы нәселдән пар сайларга тиеш, безгә шуны киңәш итәргә кирәк. Матур гаилә корып яхшы нәсел калдырырлык булсын. Акылның күпмедер чиге бар: башны артык эшләтәсе килми, әмма тилелекнең чиге юк. Бүген күп илләрдә, күп җирләрдә эт-мәчеләрдән һәм кызлардан күргәзмәләр вә конкурслар ясыйлар, арасыннан иң матурын сайлыйлар. Чибәрлек конкурсларыннан аермалы буларак, эт-мәчеләрнең токымы (нәселе) турында документы – паспорты булмаса, ул күргәзмәдә катнаша алмый. Авыл халкы сыер алса да, нәселен, холкын тикшереп ала. Байлар өйләрендә асраган этләрнең «нәселе»н яхшы белә һәм бу турыда горурланып сөйли. Ни кызганыч, без күп вакыт хатыныбызныкын гына түгел, үз нәсел-нәсәпләребезне дә белмибез. Селекция дигән фән кануны буенча, яхшы нәселдән генә яхшы нәсел кала. Бүгенге заманда уңай нәтиҗәле фермаларда селекция буенча эш алып барыла. Ихтималлылык теориясе буенча, очраклы ике эшнең берсе генә уңышлы була. Илебездә дә очраклы рәвештә төзелгән гаиләләрнең яртысыннан күбрәге таркала. Ил яхшы булсын өчен, аның халкы яхшы булырга тиеш; халкы яхшы булсын өчен, генофонд (нәсел) яхшы булу шарт. Бала урынына эт тәрбияләп кенә генофондны яхшыртып булмый.

Һәркайсыбызның бурычы – үзебездән соң безгә караганда да яхшырак бала калдыру, берне генә түгел, берничәне. Хакыйкатьтә, дөньяда чишәсе бер генә мәсьәлә (проблема) бар, ул – яхшы тәрбияле бала үстерү. Бер генә һөнәр (профессия) бар, ул – эти-әни булу. Әгәр дә кешелек дөньясы үзенең эти-әни вазыйфасын җиренә җиткереп үтәп, бала тәрбияләү мәсьәләсен хәл итә алса, башка проблемалар үзеннән-үзе чишелеш юлын табачак.

Халык хуҗалыгының бер генә тармагы да җитештерүне киңәйтмәсә, алга китә алмый. Гаиләне халык хуҗалыгының балалар җитештерү тармагы дип карасак, нәсел яхшырсын, киңәйсен дисәк, гаиләдә ким дигәндә өч бала булырга тиеш.

www.darul-kutub.com

Һәр гаиләдә өч бала да үстерә алмаган җәмгыятьнең, нәселнең киләчәге юк.

**Сакларга кирәк өченче әйбер – җан.** Бүген күпме генә зарлансак та, тормыш, без үскән чор белән чагыштырганда, күпкә әйбәт. Өйләр дә зур, һәркемдә диярлек машина бар, ризык-кием күп, балалар гына аз. Кайвакыт исәпләп утырам: без үскәндә авылда һәр йортка уртача 3 бала туры килә иде, бүген, аяныч ки, ике йортка бер бала туры килә. Бу фаҗига түгелмени?! Оптимизациягә эләгеп ябылган мәктәпләрнең күп булуында – гаиләсендә 3 бала да тәрбияләмәгән әти-әнинең өлеше зур. «Элек эш бар иде, хәзер эш юк», – дип акланмакчы булабыз. Әйе, элек эш бар иде, бригадир эшкә куып йөрде, ләкин түләве юк иде. 6-7, 7-8 бала үстергән әби-бабаларыбыз бер тиенсезгә (хезмәт көненә) эшләгән, пенсия дә узган гасырның 60 нчы елларында гына бирелә башлады. Алар балалар үстерергә-тәрбияләргә үзләрендә көч тапкан, чөнки алар намаз укучылар яки намаз укучыдан дөньяга килгән кешеләр иде. Эшләгән кешегә бүген дә эш бар, әмма иман качкан, иман юк, намаз, тәһарәт-госел юк – шуңа күрә рәт тә юк. Аллаһка мәхәббәте булмаган кешенең баланы сөяргә мәхәббәте (ярату хисе) була алмый, ул баланы аның иреген чикләүче, аңа кешечә яшәргә комачаулаучы, тынычлыгын алучы итеп карый. Аллаһка түгел, үз-үзебезгә табынабыз, үзебезнең нәфесебез өчен генә яшибез, ә бу – яшәү түгел, җан асрау *(существование)* гына. Шуңа күрә җан кыябыз, әстәгъфирулла. Бала төшерү буенча Русия дөньяда беренче урында тора. Кыямәт көнендә үтерелгәннәр үтерүчеләр янына китерелеп, «Ни өчен үтердең?» дип сорау бирелер. Үтергәннәр акланырлар ди: «Ул миңа зыян салды, куркыныч тудырды». Шулвакыт, дөньяга киләсе булып та, тумый калган (төшерелгән) балаларның җаннарын алып килерләр дә: «Боларның гаепләре нидә иде?» – диярләр. Кайвакыт, бер кечкенә сабый, я яшь кеше үлеп китсә, елый-елый, «бердәнберемне алды» дип, Аллаһка тел тидерәләр. Сорау бирәсе килә: «Дөньяга киләсе ничә җанны үзең юк иттең?»

www.darul-kutub.com

Җан кыюга этәргән тагын бер әйбер – хәрәм ризык. Хәрәм ризык кешедә ихтыяр көчен бетерә һәм кеше үз-үзен контрольдә тота алмый башлый. Аракы аркасында илебездә елына 700-900 мең кеше үлә, тәмәке аркасында – 400 мең; СПИДтан – 125 мең кеше, әле наркоманнар бу исәпкә кермәгән.

Бала дөньяга аваз салуга ук аракы эчә башламый. Динебездә урлау, дуңгыз ите, үләксә ашау, бугаз каны эчү, бисмилләәһ әйтми суелган ит куллану – хәрәм. Җанын саклыйм дисә, гаилә башлыгының өендәгеләрне хәләл ризык белән тәэмин итүе лазем. Баланың уң кул белән ашавы, ашар алдыннан «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим» дип әйтүе – бар да игътибар үзәгендә булырга тиеш. Җанны саклау – тормышны Аллаһ кануннары буенча алып бару ул. Аллаһ Раббыбыз Коръәндә (**«Бәкара (Сыер)» сүрәсенең 286 нчы аяте**): **«Ләһәә мәә кәсәбәт үә гәләйһәә мәктәсәбәт»**, ягъни: **«Мин кушканны үтәвегезнең файдасы үзегез өчен, үтәмәсәгез, зыяны – үзегез өчен»**, – ди. Халкыбызда «намус» дигән төшенчә бар. Намус саф күңелле (чиста калебле) кешедә генә була. Аллаһ нәрсәләрне боерган – алар күңелне чистарта, нәрсәләрне тыйган – алар күңелне пычрата. Намусны саклау – Аллаһ кушканнарны үтәү дигән сүз.

**Дүртенче сакларга кирәк әйбер – мал.** Гаилә башлыгы байлыкны таба да, тота да, саклый да белергә тиеш. Динебез бай яшәүдән тыймый. Ләкин байлык күңелдә түгел, кесәдә генә булырга тиеш.

Күңелне тулысынча байлык биләп алса, анда Аллаһка һәм якыннарыңа урын калмый. Байлык хәләл юл белән табылырга һәм тиешле урынга тотылырга (зәкят-гошерләре чыгарылырга) тиеш. Аллаһ Раббыбыз Коръәндә («Мөлек (Падишалык)» сүрәсе, 15 нче аять): **«Һү-үәлләзии җәгәлә ләкүмүл әрда зәлүүләң фәмшүү фии мәнәкибиһәә үә күлүү мирризкыйһ. Үә иләйһиннүшүүүр»**, ягъни: **«Җирне мин сезгә уңайлы итеп яраттым, җирдә йөрегез, кәсеп итегез, әмма минем хозурыма кайтасыгызны онытмагыз»**, – ди. Остазым Габделхак абый Садыйков: «Байлык дәһриләр өчен дәгъвәт

www.darul-kutub.com

булып тора», – дип әйтә иде. Хәзерге көндә без халкы 70-80 ел динсезлектә тәрбияләнгән илдә яшибез. Безнең халык өчен матди байлык – дәрәҗә. Без, мөселманнар, халык хуҗалыгының төрле тармакларында тырышып эшләмәсәк, балаларыбызга яхшы дөньяви белемнәр бирмәсәк, начар яшәү юлына бассак, динсезләр: «Әнә, алар (ягъни мөселманнар) кебек булмагыз», – диячәк. Без, телибезме-теләмибезме, ислам диненә каршы чакыра торган күргәзмә әсбап ролен үтәячәкбез. Шуңа күрә, гыйлем алу дигәндә аңа дөньяви гыйлем дә кирә. Балаларыбыз яхшы укытучы, табиб, юрист, җитәкче, эшмәкәрләр дә булсын, иманлы да булсын. Иманлы, намуслы кешеләр халык хуҗалыгының кайсы гына тармагында булса да (турыдан-туры хәрәм җитештермәгәндә), аннан дингә зыян юк. Бер намаз белән икенче намаз арасында эшләгән һәр хәләл эш савап булып языла. Кайбер яшьләребез эшкә, хезмәткә салкын карый. Гаиләне тәэмин итү – ваҗиб (өскә йөкләнгән бурыч). Ир кеше хатынын ризык, кием, яшәү урыны белән тәэмин итәргә тиеш. Ачтан үлмәслек итеп кенә түгел (хатыны үскән йорттагы социаль хәленә карап). Әгәр без, мөселманнар, гаиләбезне мөселман булмаган кешеләрдән күпкә начаррак тәэмин итсәк, дин дошманнары бу күренешне исламга каршы файдаланачак. Әлбәттә, хатын-кыз сабыр булырга тиеш. Бер сәгать авырлыкка сабыр итү – бер ел нәфел гыйбадәттән хәерлерәк. Әмма ир кеше үз өстенә йөкләнгән ваҗиб гамәлне үтәргә тиеш. Ваҗибне калдыру – шулай ук гөнаһ.

Имам Әбу Хәнифәнең бер шәкерте начар киенеп йөри икән. Көннәрдән бер көнне, хәзрәт аңа, яхшы кием алу өчен, акча тәкъдим итә. Шәкерт остазына үзенең яхшы кием алырлык мөмкинлеге булуын, начар киемнән йөрүе – тәкъвалыкка омтылуы икәнен аңлата. Имам Әбу Хәнифә аңа: «Сиңа Аллаһның рәхмәте булган икән, синдә аның әсәре күренергә тиеш», – дигән.

Бер кеше мәчеттән, фарыз намаз бетүгә үк, ашыгып чыгып китә, сәхабәләр бу күренешкә ризасызлык белдерә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.): «Ачуланмагыз, аның

гаиләсе зур, гаиләсен туйдырыр өчен ул хәләл кәсепкә китте, ягъни бер фарыздан икенче фарызга күчте. Ә без фарыздан сөннәткә күчтек», – дигән. Бу хәдистән гаиләне кайгыртуның фарыз дәрәҗәсендә торуы күренә. Бүген кайберәүләрнең, намаз тәмамлангач, тәсбих тартмыйча, Коръән тыңламыйча баскычта, киенү бүлмәсендә әкият сатып торуы – фарыздан фарызга күчү түгел, ул – чын әдәпсезлек. Пәйгамбәребез (с. г. в.): «Әдәбе булмаганның сөннәте кабул булмас, сөннәте кабул булмаганның бер гамәле дә кабул булмас», – дигән. Эшең бар икән – рәхим ит (ишек ачык), эшеңә ашык; барасы җиреңюк икән – урыныңда утыр. «Коръән укучыга – бер хәрефкә, ким дигәндә, ун савап, тыңлаучыга – бер савап» дигән хәдис гамәлдән чыгарылмаган бит.

Аллаһның рәхмәте белән, корган нигезләребездә, яшәгән җирләребездә үзебезчә (милли тормыш белән) яшик, татарча уйлыйк, үз ана телебездә сөйләшик. Үз милләте, үз халкы белән горурлана һәм аңа хезмәт итә, татарча уйлый вә сөйләшә торган балалар тәрбияләп калдырыйк, изге эшләребездә, изге ниятләребездә Аллаһ ярдәмче булса иде. Телләребезгә, күңелләребезгә сабырлыклар биреп, калган гомерләребезне Аллаһ риза булырлык итеп үткәрүләр һәркайсыларыбызга да насыйп булсын.

*Мин елмаям сезгә уен-көлкеле сүзләр сөйләп,*

*Кайвакыт: бу елмаюым ачы күз яшьләре аша.*

*Әгәр сүзләрем кәефегезне күтәрсә,*

*Мин сөенәм, шатлыгым чиктән аша.*

www.darul-kutub.com

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим**

## Дүртенче туган көн

*Якутлар табыладыр вакыт белән,*
*Вакытлар табылмыйдыр якут белән.*
*(Габделҗаббар Кандалый)*

**Әгүүзү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗииим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим. Әлхәмдүлилләәһи раббил гәәләмииин. Үәссаләәтү үәссәләәмү гәләә расүүлинә Мүхәммәдиү үә гәләә әәлиһи үә әсъхәәбиһи әҗемәгииин.**

**Газиз дин кардәшләрем, әссәләәмүгәләйкүм үә рахмәтүллааһи үә бәракәәтүһ!**

Аллаһ Раббыбызның бу дөньяда безгә биргән иң зур нигъмәте — вакыт. Шул бүләкне, ягъни вакытны ничек үткәрүебезгә карап, хакыйкый булган мәңгелек тормышыбыз тәгаенләнә. Әлбәттә, без гафил (сизми-абайламый, белми калучы). Кулыбызда нинди хәзинә барын, аны ничек файдаланып буласын уйламыйбыз. Исебезгә төшсә — гомер үткән, үләр вакыт җиткән. Әгәр гомеребезнең нинди хәзинә икәнен аңласак, без аның бер минутын да бушка, заяга үткәрмәс идек, һәр сулышыбызны Аллаһка шөкер итеп, һәр мизгелебезне игелек кылырга омтылып, бер изге гамәлдән икенчесенә генә күчеп үткәрер идек.

www.darul-kutub.com

Бүгенге көндә бик күп календарьлар бар, аларда истәлекле даталар, бәйрәмнәр генә дә нихәтле! Без бер датадан – икенчесенә, бер бәйрәмнән икенче бәйрәмгә әзерләнеп, бәйрәм итеп гомер үткәрәбез. Эшләргә, гамәл кылырга вакыт калмый.

Кызганыч ки, күп бәйрәмнәрне үткәрүебез бирән булганчы ашауга һәм лыгыр булганчы эчүгә, ягъни хайвани сыйфатларны арттыруга, нәфесне ирекка чыгаруга, шәһвәтне котыртуга кайтып кала. Артыгын ашау да хәмер эчү кебек үк гөнаһ бит. Исереп егылган кеше үзенә золым кылса, нәфесен аздырган кеше һәрвакыт башкаларга зарар китерергә мөмкин. Эчүчелек – нәфесне йөгәнли алмау чире.

Әлбәттә, бәйрәм дә итәргә кирәк — акыл белән, тиешле кысадан чыкмыйча. Гомәр радияллаһу ганһу: *«Сезнең күңелләрегезнең дә сезнең өстә хаклары бар, күңелләрегезне вакыт-вакыт ирекка чыгарып алыгыз, югыйсә каты бәгырьле, тар күңелле булырсыз»*, – дигән.

Димәк, һәр бәйрәм күңелне тәрбияләү һәм рухый яктан биеклеккә күтәрелү булырга тиеш. Уразаны гына алыйк. Динсезләр: «Ач тору нинди бәйрәм булсын?» – диләр. Әйдәгез, уйлап карыйк: дуслар белән очрашу — зур сөенеч, зур бәйрәм; дошманыңны җиңү — аннан да зуррак бәйрәм. Дошманнарын җиңү көнен һәр халык, һәр милләт ил күләмендә бәйрәм итә. Безнең илдә ул — 9 Май. Ә иң зур дошманыбыз кем соң безнең? Шайтан дисезме? Юк. Пәйгамбәребез (с. г. в.): *«Сезнең нәфесегез 70 шайтаннан да яманрак»,* – дигән. Иң бөек җиңү — үз нәфесеңне җиңү. Уразада без, өлешчә булса да, нәфесебезне йөгәнлибез. Ашамыйча-эчмичә торып үзебезнең хайван түгеллегебезне күрсәтәбез. Ач булган хәлдә ризыгы янында яткан хайван аны ашамыйча тора алмый. Ә без исә, Аллаһның рәхмәте белән, тора алабыз — күңелебез тантана итә, җанга рәхәт. Шуңа күрә дә мөселманнар күп бәйрәмнәрен ураза тотып каршылый.

Адәм баласының бөтен гомере — акыл белән нәфес көрәше. Гомереңхаталар һәм ялгышлар җыентыгына әйләнмәсен дисәң,

акылыңны намаз белән, нәфесеңне ураза белән тәрбиялә. Акылың да, нәфесең дә тәртипсез икән — милиция дә (исемен «полиция» дип үзгәртүгә дә карамастан) синнән тәртипле кеше ясый алмый инде. Димәк, җәмгыятьтә дә тәртип була алмый, чөнки күп вакыт үзләре дә шул нәфес коллары булып кала бирә. Без кешечә яшәсен өчен Аллаһ Раббыбыз дин биргән, Коръән иңдергән, үзенең пәйгамбәрләрен җибәргән. Гомеребез, бәйрәмнәребез, яшәешебез хәрәмнәрсез, Аллаһ риза булырлык итеп үтәргә тиеш.

Бәйрәмнәрнең шактые, мөгаен, туган көн белән бәйледер: үзеңнеке, әти-әниеңнеке, әби-бабаңныкы, балалар-оныкларныкы, кода-кодагыйныкы, таныш-белешләрнеке, дус-ишләреңнеке... Кыскасы, көн дә бәйрәм, көн дә туй.

Һәркем үзенең дөньяга килүен бәйрәм итә, нәрсә бәйрәм иткәнен, ничек бәйрәм иткәнен уйлап та карамый – фикере юк…

Фикер өчен күңелеңнең чиста булуы лазем. Күңелең чиста булсын өчен Аллаһ Раббыбыз кушканнарны үтәргә, Аның тыйганнарыннан тыелырга кирәк.

Ә безнең күңелебез пычрак. Акылыбыз намаз белән тәрбия кылынмаган, шуңа күрә теләсә-нәрсә ашыйбыз, теләсә-нәрсә карыйбыз-ишетәбез, аннары шуны сөйлибез. Хакыйкатьтә исә без яшәмибез, бары күңелне генә нәҗеслибез. Югыйсә, безгә, кеше булып яшәү өчен, акыл бирелгән, аны тәрбияләү өчен биш вакыт намаз фарыз кылынган. Хайваннарга мондый нигъмәт бирелмәгән бит, ә безгә бирелгән — нигә моның кадерен белмибез?!

Күңелебез пычрак булгач, үзебездән башканы күрмибез һәм яратмыйбыз. Үзебезне генә яратучылар (эгоистлар) булып яшибез. Яныбызда безне аңламый, хәлебезгә керә белми торган чиновниклар бар икән, шулар аркылы Аллаһ Раббыбыз безгә үзебезне күрсәтә. Кызганыч, бүген күбебез миһербансыз. Ә бит диннең беренче кагыйдәсе — *«Аллаһны, ул яраткан барча кешеләрне һәм мәхлукатьне ярат»*.

www.darul-kutub.com

Сүзебез туган көн турында иде. Әйдәгез, уйлап карыйк. Кем идек тә, кем булдык? Ничә тапкыр туабыз? Ни өчен яшибез?

Без боларны белергә тиеш. Шуларны аңлап, бәһасез вакытыбызны бушка үткәрмәскә кирәк.

## Беренче туган көн

Дөнья яратылганда Аллаһ Раббыбыз барча җаннарны яратты, һәм Ул безне җан буларак мәңгелек итеп яратты. Җан мәңгелек: туган көне бар, үләчәк көне юк. Җан бер халәттән икенче халәткә генә күчә. Мисал өчен, су кебек. Суны коедан тутырасың, коедан чиләккә саласың, чиләктән чәйнеккә аласың, аннары эчәсең. Хакыйкатьтә, су юкка чыкмый. Җаннарны яраткач, Аллаһ Раббыбыз аларга үзен күрсәткән, һәм: *«Әләстү бираббикүм?»*, ягъни: *«Раббың кем?»* – дип сорау биргән *(«Әгъраф (Пәрдә, калкулык)» сүрәсенең 172 аяте).*

Җаннар бу күрешүдән соң шулкадәр тәэсирләнгән, ләззәтләнгән: аларда иң Гүзәл, иң Бөек, иң Олуг Зат булган Аллаһка әйтеп бетергесез олы мәхәббәт уянган. Җаннар бертавыштан: *«Әйе, Син – безнең Раббыбыз һәм барлыкка китерүчебез»,* -– ди, Аллаһны танып Аңа иман китерә. Бу – Кыямәт көнендә җаннар: *«Без Раббыбыз турында бернәрсә белмәдек, гафил булдык»*, – дип акланмасыннар өчен эшләнә һәм бу очрашу Аллаһ белән җаннар арасында килешү булып тора. Җаннар Аллаһны танырга, ул кушканча яшәргә вәгъдә бирә. Җаннарның Аллаһ белән очрашуы, иманлы яшәргә вәгъдә бирүе **әлмисак** дип атала.

Риваятьләрдә болай диелә. Аллаһы Тәгалә җаннарга Җирне һәм Җәннәтне күрсәткән, һәм: *«Сынар өчен мин сезне «Җир» дип аталган якты дөньяга чыгарып алам. Анда үзегезне, якыннарыгызны, минем барча мәхлүкатымны күрерсез, әмма Мине күрә алмассыз, шул кыска гына мизгел эчендә бүген китергән иманыгызга тугры кала алсагыз – мәңге җәннәттә яшәрсез»,* – дигән. Җаннарның кайберләре Җирдәге сынаудан куркып: *«Без бу сынауны үтә алмабыз, безгә Җир ләззәтләре*

*кирәк түгел, Җәннәт булса җитә»,* – дип әйткән. Җирдән баш тарткан җаннар сабый вакытта ук үлә яисә бу дөньяда гарип яки дивана булып яши. Аларның Җирдә яшәүләре — үзләрен тәрбияләгән кешеләрне җәннәтле итү – сәламәт кешеләр аларга карап шөкер итсен, намаз-уразаларын җиренә җиткереп үтәргә омтылсын өчен.

Без бүген Җир йөзендә «кеше» дигән бөек исемне йөртәбез икән, дөнья яратылгандагы килешүебезне (вәгъдәбезне) онытырга тиеш түгелбез. Тормышта кайчак вәгъдәсез кешеләр белән дә очрашырга туры килә: безнең ачуыбыз чыга, аларга үпкәлибез. «Вәгъдәңдә тормадың, килешүне үтәмәдең», – дип, кайвакыт судлашып та йөргән булабыз. Әгәр дә без Аллаһ кушканнарны үтәмичә, Аның тыйганнарыннан тыелмыйча яшибез икән, без дә вәгъдәдә тормаучылар, килешүне исәпләмәүчеләр (санга сукмаучылар) булачакбыз. Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә безнең бу эш-гамәлебездән разый булмаячак.

Җир йөзендә күпме кеше гомер сөрә, күпме кеше яшәп киткән, тагын күпме кешенең дөньяга аваз саласы бардыр... — ләкин һәркайсының беренче туган көне бар. Җаннарның барысы да бер яшьтә, тик сынау вакытлары гына төрле...

## Икенче туган көн

Дөнья яратылганда яратылган, Аллаһ Раббыбызны күреп, әлмисакта иман китергән, саф, пакь иманлы җанны, Аллаһ рәхмәте белән, фәрештәләр 4 ай да 10 көн вакытта ана карынындагы балага китереп куя, һәм без ана карынында яши башлыйбыз.

Бала сулый, ризыгы килеп тора. Ана карынындага «бала»га «әле моннан башка тагы бер дөнья бар» дип аңлатсалар, ул ышанмас та иде. Кызганыч ки, бүген күпләребез ахирәт дөньясы барлыгына ышанып җитә алмый. Югыйсә, ничекләр итеп намазны калдырырга, башка фарызларны үтәмәскә, тыныч күңел белән хәрәм эшләр эшләп ятарга мөмкин?!

Балага җан иңгәндә, ашыйсы ризыгы, эчәсе суы, сулыйсы

www.darulkutub.com

һавасы тәгаенләп (билгеләп) куела. Дөньяда без ашыга-ашыга мал җыябыз, нindидер уңышларга ирешкән кебек булабыз.

Чынбарлыкта исә, без бернәрсә дә җыймыйбыз, бәлки аны сүтәбез. Безгә бирелгән, безгә бүлеп куелган артмый да, кимеми дә. Берәүнеке икенче бер кешегә күчми (бирелми). Халкыбызда «Күп ашасаң, аз ашарсың» дигән әйтем бар, шуңа күрә исрафтан сакланырга кирәк.

Һәркемгә билгеле бер күләмдә һава «бүлеп бирелгән». Берәү аны сулау өчен файдалана, икенче берәүләр аны тәмәке тарту өчен тота. Мәсәлән, берәүнең ашыйсы ризыгы да, эчәсе суы да бар, әмма аңа дип бирелгән һава беткән. Бу кеше һава җитмәүдән, ягъни тыны бетеп үлә дә китә… Икенче бер кеше артыгын ашарга һәвәс була — әле аның сулар һавасы да, эчәр суы да бар, тик ризыгы калмаган. Ул тамагыннан ризык үтмичә дөнья куя...

Икенче туган көннән без нинди нәтиҗә чыгарырга тиеш соң? Көнләшмәскә, барыннан канәгать булырга. Синеке сиңа килә. Аллаһ Раббыбыз мал табу юлын иректе кылган, чөнки бу дөнья сынау гына. Хәләл юл белән табасыңмы, хәрәм юл беләнме — барыбер, үзеңә дигәне — үзеңә килә.

Хәрәм юл белән тапкан өчен ахирәттә җәза каралган. Ашау-эчүдә, киенүдә хис-чаманы югалтмаска кирәк. Аллаһ Раббыбыз безгә билгеләп куйган: ашыксаң, исраф итсәң тизрәк бетә. Башкалар белән бүлешсәң, сәдака итеп бирсәң — арттырырмын дигән вәгъдәсе бар. Юмартлык синең өлешне киметми.

*...Бервакыт, бик каты арыган, йончыгып беткән, тамагы ачкан бер кеше яшь гаиләгә килеп керә. Яшь парлар аны ашатып, эчертеп, кунак итеп, ял иттереп җибәрә. Ул кеше әүлия булган. Киткәндә: «Аллаһ билгеләгән байлык яшьлегегездә килсенме, картлыгыгыздамы – дога кылачакмын», – дигән. Ир кеше: «Картлык өчен сорыйм», хатын исә: «Яшьлек өчен сорыйм», – дигән. Ахыр чиктә икесе дә «яшьлектә» дип сораган. Зәкят һәм гошерләрен вакытында түләп, мохтаҗ кешеләргә*

www.darul-kutub.com

*биреп барганнары, күп кешеләрне нәфел сәдакалары биреп тә сөендергәннәре өчен Аллаһы Тәгалә картаймыш көннәрендә боларга дәүләт (байлык) биргән. Игелекле балалары арасында тыныч картлык кичергәннәр.*

## Өченче туган көн

Монысы – без билгеләп үтә торган, ягъни бу дөньяга аваз салган көнебез. Дөньяга килдеңме, сынау инде башланды дигән сүз. Һәр үткән көн, һәр мизгел, һәр сулыш безне дөньядан китәр вакытка (үлемгә) якынайта. Һәр мизгел безне я җәннәткә, я җәһәннәмгә «өстери». Исән-сау бу дөньяга килдең. Иң беренче бурычың — әлмисакта иман китергән, ана карынында 4 ай да 10 көн чакта саф, пакь көе кабул итеп алынган җанны шул хәлдә (саф, пакь килеш) Аллаһка кайтару. Әҗәл вакытын беребез дә белми. Дөрес яшәү ул — үлем гомереңнең кай җирендә куып җитсә дә, күңелең саф, изге гамәлләрең гөнаһларыңнан күбрәк булу дигән сүз. Икенче бурыч — үзеңә караганда да яхшырак балалар тәрбияләп калдыру.

Якыннарыбызны хөрмәтләп, хәләл ризыклар тулы табын янында дуслар-туганнар белән бергә җыелып, бер-береңә бүләкләр бирешеп туган көнне бәйрәм итүдә, әлбәттә, гөнаһ юк. Гөнаһ – бәйрәмнең үзендә – туган көндә түгел. Гөнаһ – бәйрәмне ничек итеп үткәрүдә, ничек итеп яшәүдә. Гомер кыска һәм ул кыска булуы белән кадерле дә — һич үләсе килми.

*Бер әби: «Рамазанда үлсәм иде», – дип дога кыла икән. Шулай рамазан аеның бер көнендә каты гына авырып киткәч: «И Раббым, әле бу рамазанда ук димәгән идем», – дия-дия елый, ди.*

Үләсе килмәсә дә, туган көнне бәйрәм итү («Үлем якынайды» дип бәйрәм итүебез) шул максаттан була түгелме инде?

Дөньяда ике генә хакыйкать бар. Берсе — Аллаһ. Ул бар, Аңа ышанырга һәм Аңа гына гыйбадәт кылырга кирәк. Икенчесе — үлем, аңа исә әзерләнергә кирәк. Үлемгә әзерләнү ул – «Үләм»

дип елап утыру да, үлемтеккә әйбер-мазар хәстәрләү дә түгел, ул — күбрәк изге гамәлләр кылырга омтылу; үз гаиләң, әти-әниең, туганнарың, күршеләрең белән бергә яшәүнең кадерен белеп калу, күркәм мөгамәлә белән санаулы көннәреңне үткәрү.

Бер мизгел дигәндә килеп җитә торган үлем безне бу тормыштан аерачак. Һәркем үз-үзенә сорау бирсә иде: «Аллаһ каршындагы, әти-әни, Ватан, милләт, туган тел, балалар һәм башка кешеләр алдында булган вазыйфаларымны җиренә җиткереп үтәдемме? Кыямәт көнендә йөзем кызармасмы?» Әгәр барысы да тәртиптә икән — бәйрәм ит, бәйрәм итүдә гөнаһ юк, бу очракта синең моңа хакың бар. Туган көн ул – балаларга бүләк бирү бәйрәме генә түгел, аларга вазыйфа йөкләү, бурычларын аңлата башлау да булсын иде: җиде яшьтә намаз өйрәнергә кереш; ун яшең тулдымы, намазыңны укый башла; балигъ булдыңмы, гаурәтләреңне капларлык киемнән йөр һәм башка фарызларыңны да калдырма. Кызганыч, балаларыбыз бүген кулланучы гына булырга өйрәнеп үсә. Әгәр дә кеше Аллаһ каршындагы бурычларын үтәргә гадәтләнмәгән икән, ул аның башкалар алдында булганын да намус белән үтәмәячәк. Бүген-иртәгә сүзләрендә тормаучы чиновникларны, вазыйфаларын үтәмәүче җитәкчеләрне сүгәбез икән, бу – безнең Аллаһ каршындагы бурычларыбызны үтәмичә яшәвебезнең чагылышы. Моннан үзебезгә сабак алыйк, күңелебезне төзәтик.

## Дүртенче туган көн

Монысы – үлеп терелгән, ягъни кабердән кубарылачак көнебез. Аллаһ Раббыбыз ул көндә булачак хәлебезне җир тормышында ни рәвешле яшәвебез белән бәйле иткән. Дөнья — ахирәтнең иген кыры. Бу дөньяда ни чәчсәк, теге дөньяда (ахирәттә) шуны урырбыз. Үлем — ахирәт дөньясына керү капкасы булып тора. Аллаһ сиңа акыл бирде, шуның кайсысына ирешерлек итеп яшисең бит. Ахирәт мәшәкатьләре, тәмуг газаплары бу дөнья хәятендәге хәрәм әйберләргә төрелгән булса, җәннәт ләззәтләре мондагы борчу-мәшәкатьләргә, вазыйфаларга яшерелә — һәркем үзе сайлый, аны сайлауда без

www.darulkutub.com

ирекле. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с. г. в.): *«Берәү үлде исә — йокысыннан уянды»,* – дигән. Бу дөнья белән генә Аллаһның нигъмәте бетми, бары Аның сынавы гына тәмамлана. Җирдә яшәешебез тукталганнан соң хакыйкый (чын) дөньяда мәңге яшисебез бар. Һәр якты көнебезне, яшәешебезнең һәр мизгелен мәңгелек бәхет-сәгадәт җәннәтенә алып барырлык итеп үткәрергә кирәк. Һәр туган көн ул – ахирәткә, ягъни дүртенче туган көнгә әзерлекнең бер этабы, Аллаһ Раббыбыз һәркайсыларыбызга да дүртенче туган көнебезне матур итеп, сөенеп каршыларлык итеп яшәүләрне насыйп вә мияссәр кылса иде.

*Югары уку йортына керергә китәр алдыннан, урта мәктәпне тәмамлаган бер яшь егет хәзрәт янына сугылып чыгарга була.*

*— Укыгач кем буласың инде, энем? — дип сораган хәзрәт.*

*— Юрист булам.*

*— Аннары?*

*— Судья, я прокурор булып эшкә урнашырмын.*

*— Ә аннары?*

*— Аннары өйләнермен, матур гаилә корып, балалар үстерермен.*

*— Ә аннан соң?*

*— Пенсиягә чыгармын, оныкларны карашырмын.*

*— Ә аннары?*

*— Хәзрәт, үлемнән качып калып булмастыр инде ул...*

*— Менә шуның өчен, энем, тормышыңның кайсы гына мизгелендә дә Аллаһны онытма, Аллаһ каршында йөзең кызарырлык эш-гамәлләр кылма, мәңгелек урының рәхәттә булсынга максат куй, шуңа омтыл.*

**Ике генә хакыйкать бар. Берсе — Аллаһ, аңа ышанырга һәм гыйбадәт кылырга кирәк. Икенчесе — үлем, аңа әзер булып торырга кирәк.**

www.darul-kutub.com

**ЛОКМАН ХӘКИМ НӘСЫЙХӘТЛӘРЕ. – Казан: Хузур-Спокойствие, 2014. – 64 бит.**

*Тулыландырылган икенче басма.*

*Книга предназначена для имамов, муэдзинов, преподвателей воскресных курсов при мечетях, а также для широкого круга читателей.*

**Одобрено к печати решением № 13-014**

**Экспертного совета ЦРО-ДУМ РТ**

*© Издательство «Хузур-Спокойствие», 1435/2014*

Формат 84х108 $^{1}/_{32}$, печатных листов: 2,5;

бумага офсетная, печать офсетная, тираж 5000 экз.

г. Казань, пр. Победы, 30, тел.: 251 47 88,

электронная почта: ipk_ppk@mail.ru

Типография «Астор и Я» г. Казань, Ахтямова, 13а.
Отпечатано в соответствии с предоставленным электронным материалом.

www.darul-kutub.com